ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**Татарстан Республикасы Бюджет кодексына һәм “Муниципаль районнарның җирле үзидарә органнарына җирлекләрнең региональ финанс ярдәме фондыннан җирлекләргә дотацияләр исәпләү һәм бирү буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен тапшыру турында” Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2014 елның 26 ноябрендә
кабул ителде

**1 статья**

Татарстан Республикасы Бюджет кодексына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 4 – 5; 2005, № 6 (II өлеш), № 10 (I өлеш), № 12 (IV өлеш); 2006, № 6 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2007, № 8, № 10; 2008, № 8 (III өлеш), № 10 (I өлеш); 2009, № 7 – 8 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2010, № 7 (II өлеш), № 12 (I өлеш); 2011, № 8 (I өлеш), № 11 (I өлеш), № 11 (II өлеш); 2012, № 11 (I өлеш); 2013, № 7, № 10, № 11 (I өлеш); 2014, № 5) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 4 статьяда:

а) түбәндәге эчтәлекле яңа сигезенче абзац өстәргә:

“әгәр Татарстан Республикасы законнары һәм алар нигезендә кабул ителгән муниципаль район уставы һәм авыл җирлекләре уставлары белән авыл җирлекләренә авыл җирлекләре территориясендә шәһәр җирлекләренең муниципаль район хәл итә торган җирле әһәмияттәге мәсьәләләре арасыннан җирле әһәмияттәге башка мәсьәләләр беркетелгән булса, федераль салымнардан һәм җыемнардан, шул исәптән махсус салым режимнарында каралган салымнардан, Россия Федерациясе Бюджет кодексы, салымнар һәм җыемнар турында Россия Федерациясе законнары нигезендә муниципаль районнар бюджетларына күчерелергә тиешле авыл җирлекләре бюджетларына керемнәр түләү нормативларын билгеләү;”;

б) сигезенче – унбишенче абзацларны тиешенчә тугызынчы – уналтынчы абзацлар дип санарга;

2) 5 статьяның 2 пунктында:

а) икенче абзацта “җирлекләр” сүзен “шәһәр, авыл җирлекләре” сүзләренә алмаштырырга;

б) дүртенче абзацта “җирлекләр” сүзен “шәһәр, авыл җирлекләре” сүзләренә алмаштырырга;

в) алтынчы абзацта тиешле сандагы һәм килештәге “җирлек” сүзен тиешле сандагы һәм килештәге “шәһәр, авыл җирлеге” сүзләренә алмаштырырга;

3) 16 статьяда:

а) 3 пунктта:

“Татарстан Республикасы Бюджет кодексы” сүзләрен “әлеге Кодекс” сүзләренә алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

“Муниципаль район вәкиллекле органының муниципаль хокукый акты белән (муниципаль район бюджеты турындагы карардан яисә гамәлдә булу вакыты чикләнгән башка карардан тыш) федераль салымнардан һәм җыемнардан, шул исәптән махсус салым режимнарында каралган салымнардан, региональ һәм (яисә) җирле салымнардан Россия Федерациясе Бюджет кодексы, әлеге Кодекс һәм (яисә) Татарстан Республикасы законы нигезендә муниципаль район бюджетына күчерелергә тиешле түләүләрнең муниципаль районның барлык авыл җирлекләре өчен бердәй нормативлары билгеләнергә мөмкин.”;

б) түбәндәге эчтәлекле 4 пункт өстәргә:

“4. Авыл җирлекләре территорияләрендә түләтелә торган бердәй авыл хуҗалыгы салымыннан Россия Федерациясе Бюджет кодексы нигезендә муниципаль районнар бюджетларына күчерелергә тиешле салым керемнәре тиешле муниципаль районнар составына керүче авыл җирлекләре бюджетларына барлык авыл җирлекләре өчен бердәй 20 процентка тигез норматив буенча күчерелә.”;

4) 17 статьяның 2 пунктында “кертергә” сүзен “кертү көненә кадәр” сүзләренә алмаштырырга;

5) түбәндәге эчтәлекле $18^1$ статья өстәргә:

“$18^1$ статья. **Бюджетлар керемнәре чыганаклары реестры**

1. Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы, Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фондына идарә итү органнары һәм муниципаль берәмлекләрнең финанс органнары Татарстан Республикасы бюджет системасы бюджетларының керемнәре чыганаклары реестрларын алып барырга тиеш.

2. Бюджет керемнәре чыганаклары реестры дигәндә Россия Федерациясе керемнәре чыганаклары исемлеге нигезендә Татарстан Республикасы бюджет системасы бюджетларының керемнәре чыганаклары буенча бюджет төзү, раслау һәм үтәү барышында барлыкка килгән бюджет керемнәре турында мәгълүмат җыелмасы аңлашыла.

3. Татарстан Республикасы бюджеты керемнәре чыганаклары реестрының, җирле бюджетлар керемнәре чыганаклары реестрларының һәм Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты керемнәре чыганаклары реестрының мәгълүмат составына, аларны булдыру һәм алып бару тәртибенә карата гомуми таләпләр Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнә.

4. Татарстан Республикасы бюджеты керемнәре чыганаклары реестры, Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты керемнәре чыганаклары реестры һәм җирле бюджетлар керемнәре чыганаклары реестрлары тиешенчә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты һәм җирле администрация билгеләгән тәртиптә булдырыла һәм алып барыла.

5. Татарстан Республикасы бюджеты керемнәре чыганаклары реестры, шулай ук Татарстан Республикасы составына керүче муниципаль берәмлекләр бюджетлары керемнәре чыганаклары реестрлары җыелмасы һәм Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты керемнәре чыганаклары реестры Россия Федерациясе Финанс министрлыгы билгеләгән тәртиптә Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан Россия Федерациясе Финанс министрлыгына тапшырыла.

6. Татарстан Республикасы составына керүче муниципаль берәмлекләр бюджетлары керемнәре чыганаклары реестрлары һәм Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты керемнәре чыганаклары реестры Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты билгеләгән тәртиптә Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына тапшырыла.";

6) $20^{1}$ статьяда:

а) 2 пунктта "билгеләнгән тәртиптә" сүзләрен "билгеләнгән тәртипләрдә" сүзләренә алмаштырырга;

б) 4 пунктның беренче абзацында "(билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы дәүләт милке объектларын кулланылышка тапшыруга бәйле вәкаләтләрдән тыш)" сүзләрен төшереп калдырырга;

7) $20^{1.2}$ статьяда:

а) 2 пунктта "билгеләнгән тәртиптә" сүзләрен "билгеләнгән тәртипләрдә" сүзләренә алмаштырырга;

б) 4 пунктның алтынчы абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"субсидияләр буенча башкарылган гамәлләрне Татарстан Республикасы Финанс министрлыгында исәпкә алу өчен дәүләт автоном учреждениесенең,

дәүләт унитар предприятиесенең хосусый счет ачу бурычын билгели торган нигезләмәләр;”;

8) 22 статьяның 7 пунктында “кварталлык һәм еллык хисапларга” сүзләрен “еллык хисапка” сүзләренә алмаштырырга;

9) $23^1$ статьяда:

а) $3^1$ пунктның беренче абзацында “җирлекләрнең” сүзен “шәһәр, авыл җирлекләренең” сүзләренә алмаштырырга;

б) $3^2$ пунктта “җирлекләрнең” сүзен “шәһәр, авыл җирлекләренең” сүзләренә алмаштырырга;

10) 29 статьяның 2 пунктындагы бишенче абзацында “нигезендә” сүзеннән соң “, әгәр Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы белән башкасы билгеләнмәгән булса,” сүзләрен өстәргә;

11) 41 статьяда:

а) икенче абзацта “Җирлекләр” сүзен “Шәһәр, авыл җирлекләре” сүзләренә алмаштырырга;

б) өченче абзацта “тиешле муниципаль берәмлекләр милкендәге җирле әһәмияттәге” сүзләрен “юллар эшчәнлеге өлкәсендә җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне җирле үзидарә органнары хәл итә торган тиешле муниципаль берәмлекләрнең җирле әһәмияттәге гомуми файдалану” сүзләренә алмаштырырга;

в) җиденче абзацта “җирлекләрнең” сүзен “шәһәр, авыл җирлекләренең” сүзләренә алмаштырырга;

12) 43 статьяда:

а) бишенче абзацта “Татарстан Республикасы бюджетыннан” сүзләрен төшереп калдырырга;

б) түбәндәге эчтәлекле яңа алтынчы абзац өстәргә:

“федераль законнарда билгеләнгән очракларда федераль бюджетка субвенцияләр;”;

в) алтынчы абзацны җиденче абзац дип санарга;

13) 44 статьяда:

а) 2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“2. Муниципаль берәмлекләр бюджетларында түләүләрнең өстәмә нормативларына алмаштырылган бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә дотациянең исәпләнгән күләменнән (дотациянең исәпләнгән күләме өлешеннән) артмаган күләмдә Татарстан Республикасы бюджет системасының башка бюджетларыннан дотацияләрнең һәм (яисә) түләүләрнең өстәмә нормативлары буенча салым керемнәренең өлеше соңгы өч финанс хисабы елының икесе дәвамында җирле бюджетның үз керемнәреннән 5 процентка артса, әлеге

муниципаль берәмлекләр, чираттагы финанс елыннан башлап, җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә башкаручы депутатлары, сайланулы вазыйфаи затлары, муниципаль хезмәткәрләр хезмәте өчен түләү һәм (яисә) җирле үзидарә органнарын тоту чыгымнарын барлыкка китерүнең Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнгән нормативларын арттырырга хокуксыз.";

б) 3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"3. Муниципаль берәмлекләр бюджетларында түләүләрнең өстәмә нормативларына алмаштырылган бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә дотациянең исәпләнгән күләменнән (дотациянең исәпләнгән күләме өлешеннән) артмаган күләмдә Татарстан Республикасы бюджет системасының башка бюджетларыннан дотацияләрнең һәм (яисә) түләүләрнең өстәмә нормативлары буенча салым керемнәренең өлеше соңгы өч финанс хисабы елының икесе дәвамында җирле бюджетның үз керемнәреннән 20 процентка артса, әлеге муниципаль берәмлекләр, чираттагы финанс елыннан башлап, Россия Федерациясе Конституциясе, федераль законнар, Татарстан Республикасы законнары белән тиешле җирле үзидарә органнары вәкаләтләренә караган мәсьәләләрне хәл итүгә бәйле булмаган чыгым йөкләмәләрен билгеләргә һәм үтәргә хокуксыз.";

в) 4 пунктта:

беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"4. Муниципаль берәмлекләр бюджетларында түләүләрнең өстәмә нормативларына алмаштырылган бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә дотациянең исәпләнгән күләменнән (дотациянең исәпләнгән күләме өлешеннән) артмаган күләмдә Татарстан Республикасы бюджет системасының башка бюджетларыннан дотацияләрнең һәм (яисә) түләүләрнең өстәмә нормативлары буенча салым керемнәренең өлеше соңгы өч финанс хисабы елының икесе дәвамында җирле бюджетның үз керемнәреннән 50 процентка артса, әлеге муниципаль берәмлекләрдә, шулай ук соңгы өч финанс хисабы елының бер һәм күбрәк елында җирле бюджет үтәлеше турында еллык хисаплары булмаган муниципаль берәмлекләрдә, чираттагы финанс елыннан башлап, әлеге статьяның 2 һәм 3 пунктларында билгеләнгән чараларга өстәп, түбәндәге чаралар гамәлгә ашырыла:";

1 пунктчада "имза салу" сүзләреннән соң "һәм аларны үтәү" сүзләрен өстәргә;

г) 5 пунктта:

икенче абзацта "җирлекләр" сүзен "шәһәр, авыл җирлекләре" сүзләренә алмаштырырга;

өченче абзацта "җирлекләр бюджетларына" сүзләрен "шәһәр, авыл җирлекләре бюджетларына" сүзләренә алмаштырырга;

д) 6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"6. Агымдагы финанс елының 1 сентябреннән дә соңга калмыйча муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы Татарстан Республикасы бюджет системасының башка бюджетларыннан чираттагы финанс елында дотацияләр

алудан яисә түләүләрнең өстәмә нормативлары буенча салым керемнәреннән тулысынча яисә өлешчә баш тарту турында карар кабул иткән очракта, чираттагы финанс елында Россия Федерациясе Бюджет кодексында, бүтән федераль законнарда һәм әлеге Кодекста каралган чикләүләр һәм чаралар җирле бюджетның үз керемнәрендә Татарстан Республикасы бюджет системасының башка бюджетларыннан дотацияләр һәм (яисә) түләүләрнең өстәмә нормативлары буенча салым керемнәре өлешен хисаплы кыскартудан чыгып кулланыла, хисаплы кыскарту исә чираттагы финанс елында киметелә торган дотацияләрнең (түләүләрнең өстәмә нормативлары буенча салым керемнәренең) гомуми күләмен соңгы өч финанс хисабы елының берсенә кертү яисә берничәсе арасында бүлү юлы белән билгеләнә.";

е) 8 пунктта "җирлекләр бюджетларына Татарстан Республикасы бюджеты исәбеннән бюджетара трансфертлар (субвенцияләрдән гайре) җирлекләренең тиешле җирле үзидарә органнары тарафыннан" сүзләрен "шәһәр, авыл җирлекләре бюджетларына Татарстан Республикасы бюджеты исәбеннән субвенцияләрдән тыш бюджетара трансфертлар шәһәр, авыл җирлекләренең тиешле җирле үзидарә органнары тарафыннан" сүзләренә алмаштырырга;

14) $44^1$ статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"$44^1$ статья. **Җирлекләрнең бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә дотацияләр**

1. Җирлекләрнең бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә дотацияләр Татарстан Республикасы бюджетында, халык санынннан һәм (яисә) бюджет тәэмин ителешеннән чыгып, җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләрен җирле үзидарә органнары тарафыннан башкаруга шәһәр җирлекләренең (шәһәр округларын да кертеп), авыл җирлекләренең финанс мөмкинлекләрен тигезләү максатларында карала.

Җирлекләрнең бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә дотацияләр җирлекләргә финанс ярдәменең региональ фондын барлыкка китерә.

Җирлекләрнең бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә дотацияләр булдыру һәм бүлү тәртибе, шулай ук шәһәр җирлекләренең (шәһәр округларын да кертеп), авыл җирлекләренең финанс мөмкинлекләрен тигезләү критерийларын билгеләү тәртибе әлеге Кодексның 2 нче кушымтасында билгеләнә.

2. Җирлекләрнең бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә дотацияләр күләме чираттагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы белән раслана һәм шәһәр җирлекләренең (шәһәр округларын да кертеп), авыл җирлекләренең күрсәтелгән муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнары тарафыннан җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләрен гамәлгә ашыру буенча чираттагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы белән билгеләнгән финанс мөмкинлекләрен тигезләү критерийларына ирешү зарурлыгыннан чыгып билгеләнә.

Чираттагы финанс елына һәм план чорына җирлекләрнең бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә дотацияләр күләмен билгеләгәндә шәһәр җирлекләренең (шәһәр округларын да кертеп), авыл җирлекләренең күрсәтелгән муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнары тарафыннан җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләрен гамәлгә ашыру буенча финанс мөмкинлекләрен тигезләү критерийлары күрсәткечен агымдагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы белән билгеләнгән күрсәтелгән критерийлар күрсәткеченнән киметү рөхсәт ителми.

3. Җирлекләрнең бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә дотация күләме, шәһәр җирлегендә, авыл җирлегендә яшәүчеләр саныннан чыгып, Татарстан Республикасының һәр шәһәр җирлеге (шәһәр округларын да кертеп), авыл җирлеге өчен бер кешегә исәпләнеп билгеләнә.

Күрсәтелгән дотацияне алу хокукына, әлеге Кодексның $44^{10}$ статьясындагы 1 пунктында күрсәтелгәннәрдән тыш, Татарстан Республикасының барлык шәһәр җирлекләре (шәһәр округларын да кертеп), авыл җирлекләре ия була.

Җирлекләрнең бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә дотацияләр шәһәр җирлекләре (шәһәр округларын да кертеп), авыл җирлекләре арасында, аларның хисаплы бюджет тәэмин ителеше дәрәҗәсеннән чыгып, тулысынча яисә өлешчә бүленергә мөмкин. Татарстан Республикасының барлык шәһәр җирлекләре (шәһәр округларын да кертеп), авыл җирлекләре, әгәр аларның хисаплы бюджет тәэмин ителеше дәрәҗәсе шәһәр җирлекләренең (шәһәр округларын да кертеп), авыл җирлекләренең хисаплы бюджет тәэмин ителешен тигезләү критерие буларак билгеләнгән дәрәҗәдән артып китмәсә, күрсәтелгән дотацияләрне алу хокукына ия була.

Шәһәр җирлекләренең (шәһәр округларын да кертеп), авыл җирлекләренең хисаплы бюджет тәэмин ителеше дәрәҗәсе бер кешегә исәпләнгән салым керемнәренә нисбәттә билгеләнә, шәһәр җирлекләре (шәһәр округларын да кертеп), авыл җирлекләре бюджетына салым керемнәре исә икътисадның һәм (яисә) салым базасының (салым потенциалының) үсеш дәрәҗәсеннән, структурасыннан һәм, халык структурасындагы аермаларны, бер кешегә исәпләнгән муниципаль хезмәт күрсәтүләр хакына тәэсир итә торган социаль-икътисадый, климатик, географик һәм башка объектив факторларны һәм шартларны исәпкә алып, Татарстан Республикасының шәһәр җирлекләре (шәһәр округларын да кертеп), авыл җирлекләре буенча шундый ук уртача күрсәткечтән чыгып алынырга мөмкин.

Җирлекләрнең хисаплы бюджет тәэмин ителеше дәрәҗәсе шәһәр җирлекләренең (шәһәр округларын да кертеп), авыл җирлекләренең салым керемнәре, бюджет хезмәт күрсәтүләре исемлеге һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең бер кешегә исәпләнгән хакына тәэсир итә торган факторларны һәм шартларны тасвирлаучы күрсәткечләре чагыштырмасын тәэмин итә торган бердәй методика нигезендә шәһәр җирлекләре (шәһәр округларын да кертеп), авыл җирлекләре буенча аерым әлеге Кодексның 2 нче кушымтасы нигезендә

шәһәр җирлекләре (шәһәр округларын да кертеп), авыл җирлекләре буенча билгеләнә.

Шәһәр җирлекләренең (шәһәр округларын да кертеп), авыл җирлекләренең хисаплы бюджет тәэмин ителеше дәрәҗәсен билгеләгәндә хисап чорында факттагы керемнәрнең һәм чыгымнарның күрсәткечләрен һәм (яисә) аерым шәһәр, авыл җирлекләре бюджетларының фаразлана торган керемнәре һәм чыгымнары күрсәткечләрен куллану рөхсәт ителми.

4. Татарстан Республикасы бюджетын төзегәндә һәм (яисә) раслаганда җирлекләрнең бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә дотацияләр, муниципаль берәмлекләрнең вәкиллекле органнары белән килештереп, шәһәр җирлекләре (шәһәр округларын да кертеп), авыл җирлекләре бюджетларына физик затлар керемнәренә салымнан түләүләрнең өстәмә нормативлары белән тулысынча яисә өлешчә алмаштырылырга мөмкин.

Күрсәтелгән өстәмә норматив әлеге Кодексның 1 нче кушымтасы нигезендә җирлекләрнең бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә дотациянең исәпләнгән күләменең (дотациянең исәпләнгән күләме өлешенең) бердәй методикасы нигезендә тиешле шәһәр, авыл җирлеге территориясе буенча Татарстан Республикасының берләштерелгән бюджетына күчерелергә тиешле физик затлар керемнәренә салымның фаразлана торган күләменә нисбәте буларак исәпләнә.

Физик затлар керемнәренә салымнан түләүләрнең өстәмә нормативлары кимендә өч елга билгеләнә. Агымдагы финанс елы дәвамында шәһәр, авыл җирлекләре бюджетларына түләүләрнең күрсәтелгән нормативларын үзгәртү рөхсәт ителми.

Шәһәр, авыл җирлеге тарафыннан физик затлар керемнәренә салымнан түләүләрнең өстәмә нормативлары буенча бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә дотациянең исәпләнгән күләменнән (дотациянең исәпләнгән күләме өлешеннән) артык алынган акчалар Татарстан Республикасы бюджетына кире алынмаска һәм (яисә) алга таба җирле бюджетларга финанс ярдәме билгеләгәндә исәпкә алынмаска тиеш.

Физик затлар керемнәренә салымнан түләүләрнең өстәмә нормативлары буенча җирлекләрнең бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә дотациянең исәпләнгән күләменнән (дотациянең исәпләнгән күләме өлешеннән) кимрәк күләмдә акчалар алуга бәйле рәвештә шәһәр, авыл җирлекләре бюджетларындагы югалтулар Татарстан Республикасы бюджетыннан компенсацияләнмәскә һәм (яисә) җирле бюджетларга алга таба бюджетара трансфертлар бүлгәндә исәпкә алынмаска тиеш.

5. Татарстан Республикасы законы белән муниципаль районнарның җирле үзидарә органнарына Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән шәһәр, авыл җирлекләре бюджетларына дотацияләр исәпләү һәм бирү буенча Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары вәкаләтләре тапшырылырга мөмкин.

Күрсәтелгән законда Россия Федерациясе Бюджет кодексы һәм әлеге статья таләпләренә туры килә торган муниципаль районнар бюджетларына әлеге

вәкаләтләрне гамәлгә ашыруга субвенцияләрне исәпләү тәртибе (методикасы) һәм шәһәр, авыл җирлекләре бюджетларына дотацияләр күләмен муниципаль районнарның җирле үзидарә органнары тарафыннан исәпләү тәртибе (методикасы), шул исәптән физик затлар керемнәренә салымнан түләүләрне исәпләү һәм аларны алмаштыра торган өстәмә нормативларны билгеләү тәртибе (методикасы) каралырга тиеш.

Муниципаль районнарның җирле үзидарә органнарына Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының әлеге пунктның беренче абзацында күрсәтелгән вәкаләтләре бирелгән очракта, муниципаль районнар территориясендәге шәһәр, авыл җирлекләренә дотацияләр бирү өлешендә җирлекләрнең бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә дотацияләр Татарстан Республикасы бюджеты составында каралмый. Бу чакта шәһәр, авыл җирлекләренең бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә муниципаль районнар территорияләре составына керүче шәһәр, авыл җирлекләре бюджетларына күчерелергә тиешле дотацияләр, бер кешегә исәпләгәндә халык саныннан чыгып, муниципаль районнар бюджетлары арасында бердәй методика нигезендә бүленә.

Шәһәр, авыл җирлекләре бюджетларына дотацияләр исәпләү һәм бирү буенча вәкаләтләр башкаруга муниципаль район бюджетына Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән алынган субвенцияләр җирлекләрнең бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә дотацияләргә кертелә.

6. Җирлекләрнең бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә дотацияләрне шәһәр, авыл җирлекләре арасында бүлү һәм (яисә) шәһәр, авыл җирлекләре бюджетларына физик затлар керемнәренә салымнан аларны алыштыручы түләүләрнең өстәмә нормативлары чираттагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы белән раслана.

Җирлекләрнең бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә дотацияләрнең шәһәр, авыл җирлекләре арасында бүлеп бирелмәгән күләмен күрсәтелгән дотацияләрнең план чорының беренче елына расланган гомуми күләменең 20 процентыннан һәм күрсәтелгән дотацияләрнең план чорының икенче елына расланган гомуми күләменең 20 процентыннан артык булмаган күләмдә план чорына раслау рөхсәт ителә.

Чираттагы финанс елына һәм план чорының беренче елына һәр шәһәр, авыл җирлеге бюджетына җирлекләрнең бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә дотация күләме агымдагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджетында шәһәр, авыл җирлекләренең бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә дотациянең тиешенчә план чорының беренче елына һәм план чорының икенче елына расланган күләменнән кимрәк була алмый, моңа федераль законнар белән Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнарын арттыруга һәм (яисә) керемнәрен киметүгә китерә торган үзгәрешләр кертү очраклары керми.

Муниципаль районнарның вәкиллекле органнарына Татарстан Республикасы бюджетыннан җирлекләрнең бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә

дотацияләр исәпләү һәм бирү буенча Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары вәкаләтләре бирелгән очракта, күрсәтелгән дотацияләрне тиешле муниципаль районның шәһәр, авыл җирлекләре арасында бүлү һәм (яисә) физик затлар керемнәренә салымнан аларны алыштыручы түләүләрнең өстәмә нормативлары муниципаль район бюджеты турында муниципаль районның вәкиллекле органы карары белән раслана.”;

15) $44^2$ статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“$44^2$ статья. **Муниципаль районнарның (шәһәр округларының) бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә дотацияләр**

1. Муниципаль районнарның (шәһәр округларының) бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә дотацияләр Татарстан Республикасы бюджетында муниципаль районнарның (шәһәр округларының) бюджет тәэмин ителешен тигезләү максатларында карала.

Муниципаль районнарның (шәһәр округларының) бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә дотацияләр муниципаль районнарга (шәһәр округларына) финанс ярдәменең региональ фондын барлыкка китерә.

Муниципаль районнарның (шәһәр округларының) бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә дотацияләр бүлү тәртибе һәм методикасы, шулай ук муниципаль районнарның (шәһәр округларының) хисаплы бюджет тәэмин ителешен тигезләү критериен билгеләү тәртибе әлеге Кодексның 5 нче кушымтасында билгеләнә.

2. Муниципаль районнарның (шәһәр округларының) бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә дотацияләр күләме чираттагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы белән раслана һәм муниципаль районнарның (шәһәр округларының) чираттагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы белән билгеләнгән хисаплы бюджет тәэмин ителешен тигезләү критериена ирешү зарурлыгыннан чыгып билгеләнә.

Чираттагы финанс елына һәм план чорына муниципаль районнарның (шәһәр округларының) бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә дотацияләр күләмен билгеләгәндә муниципаль районнарның (шәһәр округларының) хисаплы бюджет тәэмин ителешен тигезләүнең әлеге пунктның беренче абзацында күрсәтелгән критерийны чираттагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы белән билгеләнгән критерий күрсәткеченнән киметү рөхсәт ителми.

3. Әлеге статьяның 4 пунктында күрсәтелгән дотацияләрдән тыш, муниципаль районнарның (шәһәр округларының) бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә дотацияләр хисаплы бюджет тәэмин ителеше дәрәҗәсе муниципаль районнарның (шәһәр округларының) хисаплы бюджет тәэмин ителешен тигезләү критерие буларак билгеләнгән дәрәҗәдән артып китми торган муниципаль районнарга (шәһәр округларына) бирелә.

Муниципаль районнарның (шәһәр округларының) хисаплы бюджет тәэмин ителеше дәрәҗәсе бер кешегә исәпләнгән салым керемнәренә нисбәттә билгеләнә, муниципаль район (шәһәр округы) бюджетына яисә муниципаль районның берләштерелгән бюджетына (шәһәр округы бюджетына) салым керемнәре исә икътисадның һәм (яисә) салым базасының (салым потенциалының) үсеш дәрәҗәсеннән, структурасыннан һәм, халык структурасындагы аермаларны, бер кешегә исәпләнгән муниципаль хезмәт күрсәтүләр хакына тәэсир итә торган социаль-икътисадый, климатик, географик һәм башка объектив факторларны һәм шартларны исәпкә алып, Татарстан Республикасының муниципаль районнары (шәһәр округлары) буенча шундый ук уртача күрсәткечтән чыгып алынырга мөмкин.

Муниципаль районнарның (шәһәр округларының) хисаплы бюджет тәэмин ителеше дәрәҗәсен билгеләгәндә хисап чорында факттагы керемнәрнең һәм чыгымнарның күрсәткечләрен һәм (яисә) аерым муниципаль районнар (шәһәр округлары) бюджетларының фаразлана торган керемнәре һәм чыгымнары күрсәткечләрен куллану рөхсәт ителми.

Муниципаль районнарның (шәһәр округларының) хисаплы бюджет тәэмин ителеше дәрәҗәсен билгеләү тәртибе әлеге Кодексның 5 нче кушымтасында карала. Муниципаль районнарның (шәһәр округларының) хисаплы бюджет тәэмин ителеше дәрәҗәсе әлеге Кодексның тиешенчә 6 нчы һәм 7 нче кушымталары нигезендә исәпләнә торган бюджет чыгымнары индексы күрсәткечләрен һәм шартлы салым мөмкинлекләрен кулланып билгеләнә.

Әлеге пунктта күрсәтелгән дотацияләр составында муниципаль районнарның (шәһәр округларының) хисаплы бюджет тәэмин ителеше дәрәҗәсен билгеләгәндә исәпкә алына торган аерым күрсәткечләрне (шартларны) чагылдыра торган дотацияләр аерып күрсәтелергә мөмкин. Күрсәтелгән дотацияләрне исәпләү үзенчәлекләре муниципаль районнарның (шәһәр округларының) бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә дотацияләр бүлү методикасы белән билгеләнә. Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы Законы һәм (яисә) Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарының аның нигезендә кабул ителгән норматив хокукый актлары белән күрсәтелгән дотацияләрне күчерү һәм алардан файдалану үзенчәлекләре билгеләнергә мөмкин.

4. Муниципаль районнарның (шәһәр округларының) бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә дотацияләр өлеше, әлеге Кодексның $44^{10}$ статьясының 1 пунктында күрсәтелгән муниципаль районнардан (шәһәр округларыннан) тыш, башка муниципаль районнарга (шәһәр округларына) әлеге Кодексның $2^{1}$ нче кушымтасында билгеләнгән бердәй методика нигезендә муниципаль районлагы (шәһәр округындагы) халык саныннан бер кешегә исәпләүдән чыгып бирелергә мөмкин.

5. Татарстан Республикасы бюджетын төзегәндә һәм (яисә) раслаганда муниципаль районнарның (шәһәр округларының) бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә дотацияләр, муниципаль берәмлекләрнең вәкиллекле органнары

белән килештереп, муниципаль районнар (шәһәр округлары) бюджетларына физик затлар керемнәренә салымнан түләүләрнең өстәмә нормативлары белән тулысынча яисә өлешчә алмаштырылырга мөмкин.

Күрсәтелгән өстәмә норматив әлеге Кодексның 1 нче кушымтасы нигезендә муниципаль районга (шәһәр округына) дотациянең бердәй методика нигезендә исәпләнгән күләменең (дотациянең исәпләнгән күләме өлешенең) физик затлар керемнәренә салымның фаразлана торган күләменә чагыштырмасы буларак исәпләнә.

Физик затлар керемнәренә салымнан түләүләрнең өстәмә нормативлары кимендә өч елга билгеләнә. Агымдагы финанс елы дәвамында муниципаль районнар (шәһәр округлары) бюджетларына түләүләрнең күрсәтелгән нормативларын үзгәртү рөхсәт ителми.

Муниципаль район (шәһәр округы) тарафыннан физик затлар керемнәренә салымнан түләүләрнең өстәмә нормативлары буенча бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә дотациянең исәпләнгән күләменнән (дотациянең исәпләнгән күләме өлешеннән) артык алынган акчалар Татарстан Республикасы бюджетына кире алынмаска һәм (яисә) алга таба җирле бюджетларга бюджетара трансфертлар бүленгәндә исәпкә алынмаска тиеш.

Физик затлар керемнәренә салымнан түләүләрнең өстәмә нормативлары буенча муниципаль районнарның (шәһәр округларының) бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә дотациянең исәпләнгән күләменнән (дотациянең исәп-хисап күләме өлешеннән) кимрәк күләмдә акчалар алуга бәйле рәвештә муниципаль район (шәһәр округы) бюджетындагы югалтулар Татарстан Республикасы бюджетыннан компенсацияләнмәскә һәм (яисә) алга таба җирле бюджетларга бюджетара трансфертлар бүлгәндә исәпкә алынмаска тиеш.

6. Муниципаль районнарның (шәһәр округларының) бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә дотацияләрне муниципаль районнар (шәһәр округлары) арасында бүлү һәм (яисә) муниципаль районнар (шәһәр округлары) бюджетларына физик затлар керемнәренә салымнан аларны алыштыручы түләүләрнең өстәмә нормативлары чираттагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы белән раслана.

Муниципаль районнарның (шәһәр округларының) бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә дотацияләрнең муниципаль районнар (шәһәр округлары) арасында бүлеп бирелмәгән күләмен күрсәтелгән дотацияләрнең план чорының беренче елына расланган гомуми күләменең 20 процентыннан һәм күрсәтелгән дотацияләрнең план чорының икенче елына расланган гомуми күләменең 20 процентыннан артык булмаган күләмдә план чорына раслау рөхсәт ителә.

Чираттагы финанс елына һәм план чорының беренче елына һәр муниципаль район (шәһәр округы) бюджетына муниципаль районнарның (шәһәр округларының) бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә дотация күләме агымдагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджетында муниципаль районнарның (шәһәр округларының) бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә дотациянең тиешенчә план чорының беренче елына һәм план

чорының икенче елына расланган күләменнән кимрәк була алмый, моңа федераль законнар белән Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнарын арттыруга һәм (яисә) керемнәрен киметүгә китерә торган үзгәрешләр кертү очраклары керми.”;

16) $44^4$ статьяның 3 пунктындагы беренче абзацында “критерийлары” сүзеннән соң “Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы һәм (яисә)” сүзләрен өстәргә;

17) $44^5$ статьяда:

а) “(субвенцияләрдән гайре)” сүзләреннән соң “һәм (яисә) түләүләрнең өстәмә нормативларына алмаштырылган бюджет белән тәэмин ителешне тигезләүгә дотациянең исәпләнгән күләменнән (дотациянең исәпләнгән күләме өлешеннән) сүзләрен өстәргә;

б) түбәндәге эчтәлекле икенче абзац өстәргә:

“Муниципаль берәмлекләр бюджетларына бирү өчен Татарстан Республикасы бюджетына федераль бюджеттан башка бюджетара трансфертлар бирелгән очракта, бу статьяда билгеләнгән чикләү Татарстан Республикасы бюджетыннан җирле бюджетларга бирелә торган әлеге башка бюджетара трансфертлар суммасына артырга мөмкин.”;

18) $44^6$ статьяда:

а) 7 пунктта “җирле бюджетларга” сүзләрен “муниципаль районнар һәм шәһәр округлары бюджетларына” сүзләренә алмаштырырга;

б) 9 пунктта:

беренче абзацта “Җирлекләрнең җирле үзидарә органнарына Татарстан Республикасының” сүзләрен “Шәһәр, авыл җирлекләренең җирле үзидарә органнарына Татарстан Республикасының” сүзләренә, “җирлекләрнең бюджетларына” сүзләрен “шәһәр, авыл җирлекләре бюджетларына” сүзләренә алмаштырырга;

икенче абзацта “Күрсәтелгән законнар белән” сүзләрен “Күрсәтелгән закон белән” сүзләренә, “җирлекләр” сүзен “шәһәр, авыл җирлекләре” сүзләренә алмаштырырга;

в) 10 пунктта:

икенче абзацта “Җирлекләрнең” сүзен “Шәһәр, авыл җирлекләренең” сүзләренә алмаштырырга, “җирлекләр” сүзен “шәһәр, авыл җирлекләре” сүзләренә алмаштырырга, “муниципаль районның вәкиллекле органы” сүзләрен “муниципаль район вәкиллекле органының муниципаль район бюджеты турында” сүзләренә алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле өченче яңа абзац өстәргә:

“Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының шәһәр, авыл җирлекләре бюджетларына дотацияләр исәпләү һәм бирү вәкаләтләрен үтәүгә субвенцияләрнең муниципаль районнар арасында бүленмәгән күләмен күрсәтелгән субвенцияләрнең план чорының беренче елына расланган гомуми күләменең 20 процентыннан һәм күрсәтелгән субвенцияләрнең план чорының

икенче елына расланган гомуми күләменең 20 процентыннан артмаган күләмдә план чорына раслау рөхсәт ителә.";

өченче абзацны дүртенче абзац дип санарга;

19) $44^8$ статьяда:

а) түбәндәге эчтәлекле яңа өченче абзац өстәргә:

"Россия Федерациясе Бюджет кодексының 133 һәм 140 статьяларында һәм әлеге Кодексның $44^6$ статьясында билгеләнгән очракларда шәһәр, авыл җирлекләре бюджетларына муниципаль районнар бюджетларыннан субвенцияләр;";

б) өченче абзацны дүртенче абзац дип санарга һәм анда "җирлекләр" сүзен "авыл, шәһәр җирлекләре" сүзләренә алмаштырырга;

в) дүртенче һәм бишенче абзацларны тиешенчә бишенче һәм алтынчы абзацлар дип санарга;

г) алтынчы абзацны җиденче абзац дип санарга һәм анда "җирлекләр" сүзен "шәһәр, авыл җирлекләре" сүзләренә алмаштырырга;

20) $44^9$ статьяда:

а) 2 пунктта татар телендәге текст үзгәрешсез кала;

б) 4 пунктта:

"бюджетыннан бюджет тәэмин ителешен" сүзләрен "бюджетыннан җирлекләрнең бюджет тәэмин ителешен" сүзләренә алмаштырырга, "җирлекләргә бирелә" сүзләрен "шәһәр, авыл җирлекләренә бирелә" сүзләренә алмаштырырга, "шушы муниципаль район" сүзләрен "шушы муниципаль районның шәһәр, авыл" сүзләренә алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

"Җирлекләрнең хисаплы бюджет тәэмин ителеше салым базасына (салым потенциалына) бәйле рәвештә шәһәр һәм авыл җирлекләре бюджеты бер кешегә исәпләнгәндә алынырга мөмкин булган салым керемнәренең һәм, халык структурасында аерымлыкны, социаль-икътисадый, климатик, географик һәм башка объектив факторларны һәм бер кешегә исәпләнгән муниципаль хезмәт күрсәтүләр хакына йогынты ясый торган шартларны исәпкә алып, әлеге муниципаль район җирлекләре буенча шундый ук уртача күрсәткечнең нисбәте белән билгеләнә.

Хисаплы бюджет тәэмин ителеше дәрәҗәсе шәһәр һәм авыл җирлекләре буенча шәһәр һәм авыл җирлекләренең салым керемнәре чагыштырмасын, бюджет хезмәт күрсәтүләренең һәм бер кешегә исәпләнгән муниципаль хезмәт күрсәтүләр хакына тәэсир итә торган факторларны һәм шартларны тасвирлаучы күрсәткечләрнең исемлеген тәэмин итә торган бердәй методика ярдәмендә җирлекләр буенча билгеләнә һәм шәһәр, авыл җирлекләре өчен аерым да билгеләнергә мөмкин.";

21) $44^{10}$ статьяда:

а) 1 пунктта “җирлекләрнең” сүзен “шәһәр, авыл җирлекләренең” сүзләренә алмаштырырга, “икеләтелгән” сүзен “1,3 тапкырга арттырылган” сүзләренә алмаштырырга, “җирлекләр” сүзен “шәһәр, авыл җирлекләре” сүзләренә алмаштырырга;

б) 2 пунктта:

“җирлекләр” сүзен “шәһәр, авыл җирлекләре” сүзләренә алмаштырырга, “бирелә торган” сүзләрен “күчерелә торган” сүзләренә алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле яңа икенче абзац өстәргә:

“Муниципаль районнарның вәкиллекле органнарына Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының җирлекләрнең бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә дотацияләр исәпләү һәм бирү вәкаләтләре тапшырылган очракта, муниципаль районнар территорияләре составына керүче җирлекләр бюджетларыннан бу субсидияләр әлеге Кодексның 44[1] статьясының 5 пунктындагы икенче абзацында билгеләнгән тәртиптә муниципаль районнар бюджетлары арасында бүлү өчен Татарстан Республикасы бюджеты керемнәрендә һәм чыгымнарында исәпкә алына.";

икенче абзацны өченче абзац дип санарга һәм анда “бирелә торган” сүзләрен “күчерелә торган” сүзләренә алмаштырырга;

в) 3 пунктта:

беренче абзацта “ике тапкырга” сүзләрен “1,3 тапкырга” сүзләренә алмаштырырга, “җирлекләр” сүзен “шәһәр, авыл җирлекләре” сүзләренә алмаштырырга;

икенче абзацта “җирлекләр” сүзен “шәһәр, авыл җирлекләре” сүзләренә алмаштырырга;

дүртенче абзацта “икеләтелгән” сүзен “1,3 тапкырга арттырылган” сүзләренә алмаштырырга;

г) 5 пунктның икенче абзацында “таләпләрне үтәмәгән” сүзләреннән соң “һәм (яисә) җирле үзидарә органнары муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органының муниципаль берәмлек бюджеты турындагы карарын Татарстан Республикасы бюджетына бюджетара субсидияләр күчерү өлешендә үтәмәгән” сүзләрен өстәргә;

22) 44[11] статьяда:

а) исемендә “җирлекләр” сүзен “шәһәр, авыл җирлекләре” сүзләренә алмаштырырга;

б) 1 пунктта “җирлекләр” сүзен “шәһәр, авыл җирлекләре” сүзләренә алмаштырырга;

в) 3 пунктта “җирлекләре” сүзен “шәһәр, авыл җирлекләре” сүзләренә алмаштырырга, “җирлекләрнең” сүзен “шәһәр, авыл җирлекләренең” сүзләренә алмаштырырга;

г) 4 пунктта “җирлекнең” сүзен “шәһәр, авыл җирлекләренең” сүзләренә алмаштырырга;

23) 44[12] статьяда:

а) исемендә “җирлекләр” сүзен “шәһәр, авыл җирлекләре” сүзләренә алмаштырырга;

б) “җирлекләр” сүзен “шәһәр, авыл җирлекләре” сүзләренә алмаштырырга;

24) $44^{13}$ статьяда:

а) исемендә “җирлекләр” сүзен “шәһәр, авыл җирлекләре” сүзләренә алмаштырырга;

б) “җирлекнең” сүзен “шәһәр, авыл җирлекләренең” сүзләренә алмаштырырга, “җирлекләр” сүзен “шәһәр, авыл җирлекләре” сүзләренә алмаштырырга;

25) 45 статьяга түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

“Бюджет процессында катнашучылар, Россия Федерациясе Бюджет кодексында һәм әлеге Кодекста билгеләнгән бюджет вәкаләтләре турындагы белешмәләрне бюджет процессында катнашучылар реестрына, шулай ук бюджет процессында катнашмый торган юридик затларның әлеге Кодексның 49 статьясында каралган тәртиптә төзелүче һәм алып барылучы реестрына кертү шарты белән, бу бюджет вәкаләтләрен башкарырга хокуклы.”;

26) 47 статьяда:

а) 1 пунктның өченче абзацында тиешле килештәге “җирлек” сүзен тиешле килештәге “шәһәр, авыл җирлеге” сүзләренә алмаштырырга;

б) 2 пунктның өченче абзацында тиешле килештәге “җирлек” сүзен тиешле килештәге “шәһәр, авыл җирлеге” сүзләренә алмаштырырга;

27) 49 статьяда:

а) түбәндәге эчтәлекле яңа утыз бишенче абзац өстәргә:

“Россия Федерациясе Бюджет кодексында башкасы билгеләнмәгән булса, Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнарының максатчан статьялары исемлеген һәм кодларын, шулай ук Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты чыгымнарының максатчан статьялары исемлеген һәм кодларын билгели;”;

б) түбәндәге эчтәлекле утыз алтынчы яңа абзац өстәргә:

“Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фондының идарә органнары һәм (яисә) алар карамагындагы казна учреждениеләре баш администраторлары булган Татарстан Республикасы бюджеты кытлыгын финанслау чыганакларының төрләре кодлары исемлеген раслый;”;

в) утыз бишенче абзацны утыз җиденче абзац дип санарга һәм анда “аларны” сүзеннән соң “формалаштыру һәм” сүзләрен өстәргә;

г) утыз алтынчы – утыз тугызынчы абзацларны тиешенчә утыз сигезенче – кырык беренче абзацлар дип санарга;

д) түбәндәге эчтәлекле кырык икенче абзац өстәргә:

“Татарстан Республикасы бюджеты керемнәренең чыганаклар реестрын формалаштыра һәм алып бара;”;

е) түбәндәге эчтәлекле яңа кырык дүртенче абзац өстәргә:

“әлеге статьяда билгеләнгән вәкаләтләрне башкару өчен кирәкле документларның формаларын билгели;”;

ж) кырыгынчы абзацны кырык беренче абзац дип санарга;

28) $50^1$ статьяда:

а) түбәндәге эчтәлекле яңа унөченче абзац өстәргә:

“Татарстан Республикасы казна учреждениеләренә вакытлыча эш итү өчен кергән акчалар белән операцияләрне һәм бюджет процессында катнашмый торган, Татарстан Республикасы бюджетының казна үтәлешен гамәлгә ашыручы органда шәхси счетлары ачылган юридик затлар (аларның аерымланган бүлекчәләре) акчалары белән операцияләрне исәпкә алу өчен Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына ачылган счетлардан калган акчаларны, агымдагы финанс елының соңгы эш көненнән дә соңга калмыйча элек күчерелгән счетларына әлеге орган тарафыннан Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы билгеләгән тәртиптә кире кайтарып, Татарстан Республикасы бюджетына күчерүне гамәлгә ашыра;”;

б) унөченче – унҗиденче абзацларны тиешенчә ундүртенче – унсигезенче абзацлар дип санарга;

29) түбәндәге эчтәлекле $52^1$ статья өстәргә:

“$52^1$ статья. **Озак сроклы бюджет планлаштыруы**

1. Озак сроклы бюджет планлаштыруы Татарстан Республикасы бюджеты фаразын озак сроклы чорга төзү юлы белән гамәлгә ашырыла.

2. Озак сроклы чорга Татарстан Республикасы бюджеты фаразы дигәндә Татарстан Республикасы берләштерелгән бюджетының төп характеристикалары фаразын, гамәлдә булган чорларында Татарстан Республикасы дәүләт программаларын финанс белән тәэмин итү күрсәткечләрен, Татарстан Республикасы берләштерелгән бюджетын тасвирлый торган башка күрсәткечләр, шулай ук озак сроклы чорга Татарстан Республикасының бюджет сәясәтен булдыруның төп алымнарын үз эченә алган документ аңлашыла.

3. Озак сроклы чорга Татарстан Республикасының бюджет фаразы унике елга һәм аннан озагракка һәр алты ел саен тиешле чорга Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсеш фаразы нигезендә әзерләнә.

Озак сроклы чорга Татарстан Республикасының бюджет фаразы, тиешле чорга Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсеш фаразын һәм Татарстан Республикасы бюджеты турында кабул ителгән Татарстан Республикасы законы үзгәрешен исәпкә алып, гамәлдә булу чоры озайтылмыйча, үзгәртелергә мөмкин.

4. Озак сроклы чорга Татарстан Республикасының бюджет фаразын әзерләү һәм раслау, гамәлдә булу чоры, шулай ук аның составына һәм эчтәлегенә таләпләр, Россия Федерациясе Бюджет кодексы һәм әлеге Кодекс таләпләрен үтәп, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнә.

5. Озак сроклы чорга Татарстан Республикасының бюджет фаразы проекты (бюджет фаразына үзгәрешләр проекты) (Татарстан Республикасы дәүләт программаларын финанс белән тәэмин итү күрсәткечләреннән тыш) Татарстан Республикасы Дәүләт Советына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы проекты белән бергә кертелә.

6. Озак сроклы чорга Татарстан Республикасының бюджет фаразы (бюджет фаразына үзгәрешләр) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы рәсми басылып чыккан көннән ике айдан да артмаган чорда раслана (расланалар).";

30) 53 статьяның 2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"2. Татарстан Республикасы бюджетын төзү түбәндәгеләргә нигезләнә:

1) Россия Федерациясе Президентының Россия Федерациясе Федераль Собраниесенә юлламасындагы Россия Федерациясендә бюджет сәясәтен (бюджет сәясәтенә таләпләрне) билгели торган нигезләмәләренә;

2) Татарстан Республикасы Президентының Татарстан Республикасы Дәүләт Советына юлламасына;

3) Татарстан Республикасы бюджет сәясәтенең төп юнәлешләренә һәм Татарстан Республикасы салым сәясәтенең төп юнәлешләренә;

4) Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсеше фаразына;

5) озак сроклы чорга Татарстан Республикасының бюджет фаразына (бюджет фаразы проектына, бюджет фаразына үзгәрешләр проектына);

6) Татарстан Республикасы дәүләт программаларына (дәүләт программалары проектларына, күрсәтелгән программаларга үзгәрешләр проектларына).";

31) $53^3$ статьяга түбәндәге эчтәлекле 6 пункт өстәргә:

"6. Озак сроклы чорга Татарстан Республикасының бюджет фаразын төзү максатларында Россия Федерациясе Бюджет кодексының $170^1$ статьясы һәм әлеге Кодексның $52^1$ статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнгән тәртиптә озак сроклы чорга Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсеш фаразы эшләнә.";

32) 55 статьяның 2 пунктында:

а) түбәндәге эчтәлекле яңа өченче абзац өстәргә:

“Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнгән тәртиптә әзерләнгән Татарстан Республикасы дәүләт программалары проектлары, элек расланган Татарстан Республикасы дәүләт программаларына үзгәрешләр проектлары Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына карауга кертелгәндә бер үк вакытта Татарстан Республикасы Дәүләт Советына да тапшырылырга тиеш. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Татарстан Республикасы дәүләт программалары проектларын, элек расланган Татарстан Республикасы дәүләт программаларына үзгәрешләр проектларын Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Регламентында билгеләнгән тәртиптә карауны гамәлгә ашыра.”;

б) өченче абзацны дүртенче абзац дип санарга;

в) дүртенче абзацта «ике» сүзен «өч» сүзенә алмаштырырга;

33) $55^2$ статьяда:

а) 2 пункттагы дүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Татарстан Республикасы бюджетына федераль бюджеттан бюджетара трансфертлар;”;

б) 5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“5. Татарстан Республикасы Юллар фондының бюджет ассигнованиеләрен формалаштыру һәм аларны куллану тәртибе гомуми файдаланудагы автомобиль юллары челтәре белән ел әйләнәсендә элемтәсе булмаган авыл торак пунктларына кадәр гомуми файдаланудагы каты өслекле автомобиль юлларын (федераль әһәмияттәге автомобиль юлларыннан тыш) проектлауга, төзүгә, реконструкцияләүгә, шулай ук аларны капиталь ремонтлауга һәм ремонтлауга Россия Федерациясе территориясендә җитештерелә торган автомобиль бензинына, турыдан-туры куыла торган бензинга, дизель ягулыгына, дизельле һәм (яисә) карбюраторлы (инжекторлы) двигательләр өчен мотор майларына Татарстан Республикасы бюджетына күчерелергә тиешле акцизлардан, шулай ук транспорт салымыннан Татарстан Республикасы бюджеты керемнәре исәбеннән формалаша торган Татарстан Республикасы Юллар фонды бюджет ассигнованиеләре күләменең кимендә 5 проценты кадәр, шул исәптән җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларына карата күрсәтелгән юллар эшчәнлеге өчен җирле бюджетларга субсидияләр рәвешендә бюджет ассигнованиеләрен җибәрүне күз алдында тотарга тиеш.”;

34) $60^1$ статьяның 3 пунктында:

а) $2^1$ пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“$2^1$) чираттагы финанс елына һәм план чорына бюджет ассигнованиеләрен бюджетлар чыгымнары классификациясе бүлекләре, бүлекчәләре, максатчан статьялары (Татарстан Республикасы дәүләт программалары һәм эшчәнлекнең программага карамаган юнәлешләре), чыгымнар төрләре төркемнәре һәм максатчан статьялары (Татарстан Республикасы дәүләт программалары һәм эшчәнлекнең программага карамаган юнәлешләре), чыгымнар төрләре төркемнәре, бүлекләре, бүлекчәләре буенча бүлү;”;

б) 3 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“3) чираттагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты акчаларын баш бүлүчеләр, бюджетлар чыгымнары классификациясе бүлекләре, бүлекчәләре, максатчан статьялары (Татарстан Республикасы дәүләт программалары һәм эшчәнлекнең программага карамаган юнәлешләре), чыгымнар төрләре төркемнәре буенча Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнарының ведомство структурасы;”;

35) 61 статьяның 4 пунктында:

а) икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“чираттагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджет сәясәтенең төп юнәлешләре һәм Татарстан Республикасы салым сәясәтенең төп юнәлешләре;”;

б) уникенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Татарстан Республикасы дәүләт программалары паспортлары (паспорт проектлары), күрсәтелгән паспортларга үзгәрешләр проектлары;”;

в) унөченче абзацны үз көчен югалткан дип танырга;

г) түбәндәге эчтәлекле яңа унтугызынчы һәм егерменче абзацлар өстәргә:

“озак сроклы чорга Татарстан Республикасы бюджет фаразы (бюджет фаразы проекты, бюджет фаразына үзгәрешләр проекты);

Татарстан Республикасы бюджеты керемнәре чыганаклары реестры;”;

д) унтугызынчы абзацны егерме беренче абзац дип санарга;

36) IX бүлек исемендә “бюджеты” сүзеннән соң “һәм Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты” сүзләрен өстәргә;

37) 74 статьяда:

а) исемдә “бюджетын” сүзеннән соң “һәм Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджетын” сүзләрен өстәргә;

б) түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

“Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджетын үтәү Россия Федерациясе Бюджет кодексы һәм әлеге Кодекс нигезендә гамәлгә ашырыла.”;

38) 77 статьяда:

а) исемендә “бюджетының” сүзеннән соң “(Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджетының)” сүзләрен өстәргә;

б) 2 пунктта “тәртибе” сүзеннән соң “Россия Федерациясе Бюджет кодексы һәм әлеге Кодекс нигезендә” сүзләрен өстәргә;

в) түбәндәге эчтәлекле $2^1$ пункт өстәргә:

“2[1]. Татарстан Республикасы бюджеты (Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты) җыелма бюджет язмасының расланган күрсәткечләре Татарстан Республикасы бюджеты (Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты) турында Татарстан Республикасы законына туры килергә тиеш.

Татарстан Республикасы бюджеты (Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты) турында Татарстан Республикасы законына үзгәрешләр кертү хакында Татарстан Республикасы законы кабул ителгән очракта, Татарстан Республикасы финанс министры (Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды идарә органы җитәкчесе) җыелма бюджет язмасына тиешле үзгәрешләрне раслый.”;

г) 3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“3. Татарстан Республикасы бюджетының (Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджетының) җыелма бюджет язмасына, бюджет турында Татарстан Республикасы законына үзгәрешләр кертмичә генә, Татарстан Республикасы финанс министры (Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды идарә органы җитәкчесе) карары нигезендә түбәндәге очракларда үзгәрешләр кертелергә мөмкин:

гавами норматив йөкләмәләрне үтәү өчен каралган бюджет ассигнованиеләрен кабат бүлгән очракта – бу йөкләмәләрне агымдагы финанс елында үтәү өчен бюджет турында Татарстан Республикасы законында расланган әлеге бюджет ассигнованиеләренең гомуми күләме чикләрендә, шулай ук аны расланган бюджет ассигнованиеләре составындагы резерв акчаларны кабат бүлү исәбеннән 5 процент чикләрендә арттырып;

бюджет акчаларын баш бүлүчеләрнең (бүлүчеләрнең), бюджет акчаларын алучыларның функцияләре һәм вәкаләтләре үзгәргән очракта, шулай ук дәүләт мөлкәтен тапшыруга бәйле рәвештә;

бюджет акчаларыннан түләтүне күздә тота торган суд актларын үтәгән очракта;

резерв фондлар акчаларыннан, шулай ук расланган бюджет ассигнованиеләре составында башка рәвештә резервланган акчалардан файдаланган (яңадан бүлгән) очракта, Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законында алардан файдалану күләмнәрен һәм юнәлешләрен күрсәтеп;

конкурс нигезендә бирелгән бюджет ассигнованиеләрен яңадан бүлгән очракта;

бюджет ассигнованиеләрен агымдагы финанс елы һәм план чоры арасында яңадан бүлгән очракта – тиешле финанс елына дәүләт хезмәтләре күрсәтү өчен бюджет акчаларын баш бүлүчегә бюджет турында Татарстан Республикасы законында каралган бюджет ассигнованиеләренең гомуми күләме чикләрендә;

физик һәм юридик затлардан, бюджет турында Татарстан Республикасы

законында расланган күләмнәрдән тыш, максатчан билгеләнештәге субсидияләр, субвенцияләр, башка бюджетара трансфертлар һәм кире кайтарылмый торган керемнәр алган очракта, шулай ук күрсәтелгән чаралар кыскарган (ихтыяҗ булмаган очракта кире кайтарылган) очракта;

дәүләт учреждениеләренең төре һәм дәүләт унитар предприятиеләренең оештыру-хокукый рәвеше үзгәргән очракта;

товарлар ташуга, эшләр башкаруга, хезмәтләр күрсәтүгә төзелгән дәүләт контрактлары шартлары нигезендә финанс хисабы елында түләнергә тиешле әлеге дәүләт контрактларын түләү өчен агымдагы финанс елының бюджет ассигнованиеләрен әлеге дәүләт контрактларын үтәүгә бюджет ассигнованиеләренең агымдагы финанс елы башына файдаланылмый калган суммасыннан артмый торган күләмдә Россия Федерациясе Бюджет кодексында һәм әлеге Кодекста билгеләнгән таләпләргә таянып арттырган очракта;

бюджет инвестицияләрен гамәлгә ашыруга һәм дәүләт милке объектларына капитал салуларны башкару өчен субсидияләр бирүгә бюджет ассигнованиеләрен (Татарстан Республикасы Юллар фондының бюджет ассигнованиеләреннән тыш), әлеге Кодексның 20[1] статьясындагы 2 пунктында һәм 20[1.2] статьясындагы 2 пунктында күрсәтелгән карарларга, капитал салуларны башкаруга субсидияләр бирү турында дәүләт контрактларына йә килешүләргә үзгәрешләр кертелгәннән соң, дәүләт милкендәге күрсәтелгән объектка капитал салулар башкаруны финанс белән тәэмин итү ысулын үзгәрткәндә яңадан бүлгән очракта.

Татарстан Республикасы бюджетының әлеге пунктның бишенче абзацында күрсәтелгән акчалары Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына карала.

Әлеге пунктның бишенче абзацында күрсәтелгән акчалардан файдалану тәртибе (файдалану турында, кабат бүлү турында карарлар кабул итү тәртибе) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнә.

Татарстан Республикасы бюджетының (Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджетының) җыелма бюджет язмасына әлеге пунктта билгеләнгән нигезләрдә үзгәрешләр кертү бюджет турында Татарстан Республикасы законында расланган бюджет ассигнованиеләре күләме чикләрендә башкарыла, моңа Татарстан Республикасы бюджетының (Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджетының) җыелма бюджет язмасына үзгәрешләр кертүне бюджет турында Татарстан Республикасы законында расланган чыгымнарның гомуми күләмен арттырып гамәлгә ашыру мөмкинлеген урнаштыра торган әлеге пунктның сигезенче һәм унынчы абзацларында билгеләнгән нигезләр керми.

Җыелма бюджет язмасына үзгәрешләр керткәндә гавами норматив йөкләмәләрне үтәү һәм дәүләт бурычына хезмәт күрсәтү өчен каралган бюджет ассигнованиеләрен бюджет турында Татарстан Республикасы законына үзгәрешләр кертмичә генә башка бюджет ассигнованиеләрен арттыру өчен киметү рөхсәт ителми.";

д) түбәндәге эчтәлекле 3[1] пункт өстәргә:

“3[1]. Бюджет турында Татарстан Республикасы законында Татарстан Республикасы бюджетының (Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджетының) җыелма бюджет язмасына бюджет турында Татарстан Республикасы законына үзгәрешләр кертмичә генә Татарстан Республикасы финанс министры (Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды идарә органы җитәкчесе) карары нигезендә үзгәрешләр кертү өчен өстәмә нигезләр каралырга мөмкин.”;

е) 4 пунктта:

беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“4. Татарстан Республикасы бюджетының җыелма бюджет язмасын төзү һәм алып бару тәртибендә җыелма бюджет язмасы күрсәткечләрен һәм бюджет йөкләмәләре лимитларын бюджет чараларын баш бүлүчеләр, бюджетлар чыгымнары классификациясенең бүлекләре, бүлекчәләре, максатчан статьялары (дәүләт программалары һәм эшчәнлекнең программага карамаган юнәлешләре), чыгымнар төрләре төркемнәре (төркемнәре һәм төркемчәләре) буенча раслау каралырга тиеш.”;

икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Татарстан Республикасы бюджетының җыелма бюджет язмасын төзү һәм алып бару тәртибендә бюджет йөкләмәләре лимитларын бюджетлар чыгымнары классификациясенең чыгымнар төрләре төркемнәре, төркемчәләре (төркемнәре, төркемчәләре һәм элементлары), шул исәптән бюджетның төрле максатчан статьялары һәм (яисә) чыгымнар төрләре өчен, бюджет акчаларын баш бүлүчеләр өчен дифференциацияле раслау каралырга мөмкин.”;

39) 78[1] статьяда:

а) 2 пунктның икенче абзацында “Чыгымнар” сүзләреннән соң “һәм бюджет йөкләмәләре лимитлары” сүзләрен өстәргә;

б) 3 пунктта “чыгымнар төрләре элементлары (төркемчәләре һәм элементлары) кодлары, шулай ук дәүләт идарәсе секторы операцияләрен классификацияләү кодлары буенча бюджет язмасы белән раслана торган күрсәткечләрне” сүзләрен “раслана торган бюджет йөкләмәләре лимитларын чыгымнар төрләре төркемчәләре (төркемчәләре һәм элементлары) буенча” сүзләренә алмаштырырга;

40) 80[2] статьяның 2 пунктындагы дүртенче абзацында “(төркемчәләре һәм элементлары) кодлары буенча” сүзләреннән соң “җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә” сүзләрен өстәргә, “(өстәмә статьялары) кодлары буенча” сүзләреннән соң “өстәмә рәвештә” сүзләрен өстәргә;

41) 97 статьяның 4 пунктында:

а) беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“4. Максатчан билгеләнештәге субсидияләр, субвенцияләр һәм башка бюджетара трансфертлар рәвешендә алынган, агымдагы финанс елының 1 гыйнварына файдаланылмый калган бюджетара трансфертлар үзләре алынган

бюджет кеременә агымдагы финанс елының беренче 15 эш көне эчендә кире кайтарылырга тиеш.”;

б) түбәндәге эчтәлекле яңа өченче абзац өстәргә:

“Татарстан Республикасы бюджеты акчалары баш администраторы тарафыннан максатчан билгеләнештәге субсидияләр һәм башка бюджетара трансфертлар рәвешендә алынган, финанс хисабы елында файдаланылмый калган бюджетара трансфертларга ихтыяҗ булуы (булмавы) турында карар кабул итү, шулай ук бу бюджетара трасфертларны үзләре алынган бюджетка кире кайтару, аларга ихтыяҗ булу турында карар кабул ителгән очракта, элек үзләренә бирелгән бюджет чыгымнары турында Татарстан Республикасы бюджеты акчалары баш администраторы билгеләгән тәртиптә һәм Татарстан Республикасы бюджетына күрсәтелгән акчалар кергән көннән алып 30 календарь көннән дә соңга калмыйча тапшырылган хисап нигезендә гамәлгә ашырыла.”;

в) өченче һәм дүртенче абзацларны тиешенчә дүртенче һәм бишенче абзацлар дип санарга;

42) $97^1$ статьяның 3 пунктындагы дүртенче абзацында “дәүләт идарәсе секторы гамәлләренең классификация кодлары буенча” сүзләрен “керемнәрнең ярдәмче төрләре, чыгымнар төрләре төркемчәләре һәм (яисә) элементлары, бюджетлар кытлыкларын финанслау чыганаклары төрләре кодлары буенча” сүзләренә алмаштырырга;

43) $97^3$ статьяның 2 пунктындагы өченче абзацында тиешле килештәге “җирлек” сүзен тиешле килештәге “шәһәр, авыл җирлеге” сүзләренә алмаштырырга;

44) $97^5$ статьяның дүртенче һәм сигезенче абзацларын үз көчләрен югалткан дип танырга;

45) $1^1$ нче кушымтаның 1 пунктында:

а) беренче абзацта “билгеләнә” сүзен “гамәлгә ашырыла” сүзләренә алмаштырырга;

б) бишенче абзацта “җирлекләр милкендәге” сүзләрен “җирле үзидарә органнары юллар эшчәнлеге өлкәсендә җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итә торган җирлекләрнең җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы” сүзләренә алмаштырырга, “і-муниципаль районы (шәһәр округы) милкендәге җирле әһәмияттәге” сүзләрен “җирле үзидарә органнары юллар эшчәнлеге өлкәсендә җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итә торган і-муниципаль районының (шәһәр округының) җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы” сүзләренә алмаштырырга;

в) алтынчы абзацта “Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре милкендәге җирле әһәмияттәге” сүзләрен “җирле үзидарә органнары юллар эшчәнлеге өлкәсендә җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итә торган Татарстан

Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы” сүзләренә алмаштырырга;

46) 2 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Татарстан Республикасы
Бюджет кодексына
2 нче кушымта

**ҖИРЛЕКЛӘРНЕҢ БЮДЖЕТ ТӘЭМИН ИТЕЛЕШЕН ТИГЕЗЛӘҮГӘ ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БЮДЖЕТЫННАН ДОТАЦИЯЛӘР БУЛДЫРУ ҺӘМ БҮЛҮ ТӘРТИБЕ**

1. Шәһәр, авыл җирлекләренең бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә дотацияләрдән җирлекләрнең региональ финанс ярдәме фонды (алга таба – ФФПП) хасил була.

2. ФФПП күләме ел саен чираттагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты проектын төзегәндә шәһәр җирлекләренең (шәһәр округларын кертеп), авыл җирлекләренең җирле үзидарә органнары тарафыннан җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләрен гамәлгә ашыру буенча бу муниципаль берәмлекләрнең финанс мөмкинлекләрен тигезләү критериена ирешү зарурлыгыннан чыгып билгеләнә.

ФФПП күләме әлеге Кодексның $44^{10}$ статьясында билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы бюджетына шәһәр, авыл җирлекләре бюджетларыннан күчерелә торган субсидияләр күләменнән кимрәк була алмый.

3. Авыл җирлекләренең җирле үзидарә органнары тарафыннан җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләрен гамәлгә ашыру буенча авыл җирлекләренең финанс мөмкинлекләрен тигезләү критерие ел саен чираттагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты проектын төзегәндә авыл җирлекләре арасында бер кешегә исәпләнгән шартлы салым потенциалы күләменең минималь күрсәткечен Татарстан Республикасы бюджетыннан авыл җирлекләре бюджетларына авыл җирлекләренең бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә дотацияләр яисә җирлекләрнең региональ финанс ярдәме фондыннан авыл җирлекләре бюджетларына дотацияләр исәпләү һәм бирү буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга муниципаль районнар бюджетларына субвенцияләр бирү нәтиҗәсендә арттыру зарурлыгыннан чыгып билгеләнә.

Авыл җирлекләренең җирле үзидарә органнары тарафыннан җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләрен гамәлгә ашыру буенча авыл җирлекләренең финанс мөмкинлекләрен тигезләү критерие буларак билгеләнә торган дәрәҗә түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$К_{СП} = \left(\frac{УНП^{i}_{СП}}{Ч^{i}_{СП}}\right)_{мин} \times Коэф_{ипц},$$

монда:

$К_{СП}$ – авыл җирлекләренең җирле үзидарә органнары тарафыннан җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләрен гамәлгә ашыру буенча авыл җирлекләренең финанс мөмкинлекләрен тигезләү критерие;

$УНП^{i}_{СП}$ – i-авыл җирлегенең тигезләүгә кадәр әлеге Кодексның 7 нче кушымтасында билгеләнгән Тәртип нигезендә исәпләнә торган шартлы салым потенциалы;

$Ч^{i}_{СП}$ – i-авыл җирлегенең халык саны;

$\left(\frac{УНП^{i}_{СП}}{Ч^{i}_{СП}}\right)_{мин}$ – авыл җирлекләре арасында тигезләүгә кадәр бер кешегә исәпләнгән шартлы салым потенциалы күләменең минималь күрсәткече;

$Коэф_{ипц}$– Татарстан Республикасы социаль-икътисадый үсеше фаразы нигезендә куллану бәяләре индексы.

4. Шәһәр җирлекләренең (шәһәр округларын кертеп) җирле үзидарә органнары тарафыннан җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләрен гамәлгә ашыру буенча шәһәр җирлекләрнең (шәһәр округларын кертеп) финанс мөмкинлекләрен тигезләү критерие ел саен чираттагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты проектын төзегәндә шәһәр җирлекләре (шәһәр округларын кертеп) арасында бер кешегә исәпләнгән шартлы салым потенциалы күләменең минималь күрсәткечен Татарстан Республикасы бюджетыннан шәһәр җирлекләренә (шәһәр округларын кертеп) шәһәр җирлекләренең (шәһәр округларын кертеп) бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә дотацияләр һәм (яисә) җирлекләрнең региональ финанс ярдәме фондыннан шәһәр җирлекләре бюджетларына дотацияләр исәпләү һәм бирү буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга муниципаль районнар бюджетларына субвенцияләр бирү нәтиҗәсендә арттыру зарурлыгыннан чыгып билгеләнә.

Шәһәр җирлекләренең (шәһәр округларын кертеп) җирле үзидарә органнары тарафыннан җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләрен гамәлгә ашыру буенча шәһәр җирлекләренең (шәһәр округларын кертеп) финанс мөмкинлекләрен тигезләү критерие буларак билгеләнә торган дәрәҗә түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$К_{ГП} = \left(\frac{УНП^{i}_{ГП}}{Ч^{i}_{ГП}}\right)_{мин} \times Коэф_{ипц},$$

монда:

$К_{ГП}$ – шәһәр җирлекләренең (шәһәр округларын кертеп) җирле үзидарә органнары тарафыннан җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләрен гамәлгә ашыру буенча шәһәр җирлекләренең (шәһәр округларын кертеп) финанс мөмкинлекләрен тигезләү критерие;

$УНП^{i}_{ГП}$– i-шәһәр җирлегенең (шәһәр округларын кертеп) тигезләүгә кадәр әлеге Кодексның 7 нче кушымтасында билгеләнгән Тәртип нигезендә исәпләнгән шартлы салым потенциалы;

$Ч^{i}_{ГП}$– i-шәһәр җирлегенең (шәһәр округларын кертеп) халык саны;

$\left(\frac{УНП^{i}_{ГП}}{Ч^{i}_{ГП}}\right)_{мин}$– шәһәр җирлекләре (шәһәр округларын кертеп) арасында тигезләүгә кадәр бер кешегә исәпләнгән шартлы салым потенциалы күләменең минималь күрсәткече;

$Коэф_{ипц}$– Татарстан Республикасы социаль-икътисадый үсеше фаразы нигезендә куллану бәяләре индексы.

5. Җирлекләрнең бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә ФФПП хасил итә торган дотацияләргә шәһәр җирлекләренең (шәһәр округларын кертеп) бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә дотацияләр (алга таба – ФФПГП) һәм авыл җирлекләренең бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә дотацияләр (алга таба – ФФПСП) керә.

Шәһәр җирлекләре (шәһәр округларын кертеп) бюджетлары арасында ФФПГП акчаларын бүлү әлеге Тәртипнең 6 – 15 пунктлары нигезендә башкарыла, әлеге Кодексның 44[1] статьясының 3 пунктында каралган дотацияләрнең өлешләре арасындагы нисбәт ел саен чираттагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты проектын төзегәндә билгеләнә.

Авыл җирлекләре бюджетлары арасында ФФПСП акчаларын бүлү әлеге Тәртипнең 16 – 25 пунктлары нигезендә башкарыла, әлеге Кодексның 44[1] статьясының 3 пунктында каралган дотацияләрнең өлешләре арасындагы нисбәт ел саен чираттагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты проектын төзегәндә билгеләнә.

6. Шәһәр җирлекләренең (шәһәр округларын кертеп) бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан j-шәһәр җирлеге (шәһәр округы) өчен дотация күләме, халык саныннан чыгып, түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$ФП^{j}_{ФФПГП} = V_{ФФПГП} \times \frac{Ч^{j}_{ГП}}{SUM^{n}_{j=1} Ч^{j}_{ГП}},$$

монда:

$ФП^{j}_{ФФПГП}$ – шәһәр җирлекләренең (шәһәр округларының) бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан j-шәһәр җирлеге (шәһәр округы) өчен, халык саныннан чыгып, дотация күләме;

$V_{ФФПГП}$ – халык саныннан чыгып, шәһәр җирлекләренең (шәһәр округларын кертеп) бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә ФФПГП күләме;

$Ч^{j}_{ГП}$ – j-шәһәр җирлегенең (шәһәр округының) халык саны;

n – Татарстан Республикасы бюджетыннан дотацияләр алу хокукына ия шәһәр җирлекләре (шәһәр округларын кертеп) саны.

7. Шәһәр җирлекләренең (шәһәр округларын кертеп) бюджет тәэмин

ителешен тигезләүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан дотация күләме, хисаплы бюджет тәэмин ителеше дәрәҗәсеннән чыгып, катнаш ысул белән билгеләнә. Дотацияләрнең беренче өлеше бюджет тәэмин ителешен пропорциональ тигезләү ысулын кулланып; дотацияләрнең икенче өлеше "гарантияләнгән минимум"га кадәр тигезләү ысулын кулланып бүленә:

$$D^i = D_1^i + D_2^i,$$

монда:

$D^i$ – i-шәһәр җирлеге (шәһәр округы) өчен, хисаплы бюджет тәэмин ителеше дәрәҗәсеннән чыгып, шәһәр җирлекләренең (шәһәр округларын кертеп) бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан дотациянең гомуми күләме;

$D_1^i$ – i-шәһәр җирлегенә (шәһәр округына) пропорциональ тигезләү ысулы белән бүленә торган дотацияләр өлеше күләме;

$D_2^i$ – i-шәһәр җирлегенә (шәһәр округына) "гарантияләнгән минимум"га кадәр тигезләү ысулы белән бүленә торган дотацияләр өлеше күләме.

8. Шәһәр җирлекләренең (шәһәр округларын кертеп) бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә, хисаплы бюджет тәэмин ителеше дәрәҗәсеннән чыгып, төрле ысуллар белән бүленә торган дотацияләр өлешләре арасындагы нисбәт ел саен чираттагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты проектын төзегәндә билгеләнә.

9. Дотацияләр өлешен бюджет тәэмин ителешен пропорциональ тигезләү ысулын кулланып бүлү түбәндәге формула буенча башкарыла:

$$D_1^i = d_{\text{пп}} \times V_{\text{ФФПГП}} \times \frac{H^i}{H},$$

монда:

$D_1^i$ – i-шәһәр җирлегенә (шәһәр округына) пропорциональ тигезләү ысулы белән бүленә торган дотацияләр өлеше күләме;

$d_{\text{пп}}$ – хисаплы бюджет тәэмин ителеше дәрәҗәсеннән чыгып, шәһәр җирлекләренең (шәһәр округларын кертеп) бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә пропорциональ тигезләү ысулын кулланып бүленә торган ФФПГП өлеше;

$V_{\text{ФФПГП}}$ – хисаплы бюджет тәэмин ителеше дәрәҗәсеннән чыгып, шәһәр җирлекләренең (шәһәр округларын кертеп) бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә ФФПГП күләме;

$H^i$ – шәһәр җирлекләренең (шәһәр округларын кертеп) бюджет тәэмин ителешен тигезләү критерие буларак билгеләнгән бюджет тәэмин ителеше дәрәҗәсенә i-шәһәр җирлеге (шәһәр округы) ирешү өчен кирәкле акчалар күләме;

Н – шәһәр җирлекләренең (шәһәр округларын кертеп) бюджет тәэмин ителешен тигезләү критерие буларак билгеләнгән бюджет тәэмин ителеше дәрәҗәсенә барлык шәһәр җирлекләре (шәһәр округларын кертеп) ирешү өчен кирәкле акчалар күләме.

10. Шәһәр җирлекләренең (шәһәр округларын кертеп) бюджет тәэмин ителешен тигезләү критерие буларак билгеләнгән бюджет тәэмин ителеше дәрәҗәсенә i-шәһәр җирлеге (шәһәр округы) ирешү өчен кирәкле акчалар күләмен билгеләү түбәндәге формула буенча башкарыла:

$$Н^i = ИБР^i \times Ч^i \times \left(К - БО^i_{расч}\right) \times \frac{SUM^n_{i=1} УНП^i}{SUM^n_{i=1} Ч^i},$$

монда:

$Н^i$ – шәһәр җирлекләренең (шәһәр округларын кертеп) бюджет тәэмин ителешен тигезләү критерие буларак билгеләнгән бюджет тәэмин ителеше дәрәҗәсенә i-шәһәр җирлеге (шәһәр округы) ирешү өчен кирәкле акчалар күләме;

$ИБР^i$ – i-шәһәр җирлегенең (шәһәр округының) әлеге Кодексның 6 нчы кушымтасында билгеләнгән тәртип нигезендә исәпләнә торган бюджет чыгымнары индексы;

$Ч^i$ – i-шәһәр җирлегенең (шәһәр округының) халык саны;

К – шәһәр җирлекләренең (шәһәр округларын кертеп) бюджет тәэмин ителешен тигезләү критерие;

$БО^i_{расч}$ – i-шәһәр җирлегенең (шәһәр округының) хисаплы бюджет тәэмин ителеше дәрәҗәсе;

$УНП^i$ – i-шәһәр җирлегенең (шәһәр округының) әлеге Кодексның 7 нче кушымтасында билгеләнгән тәртип нигезендә исәпләнә торган шартлы салым потенциалы;

n – Татарстан Республикасындагы шәһәр җирлекләре (шәһәр округларын кертеп) саны.

11. Шәһәр җирлекләренең (шәһәр округларын кертеп) хисаплы бюджет тәэмин ителешен тигезләү критерие ел саен чираттагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты проектын төзегәндә, муниципаль берәмлекләрнең суммар ихтыяҗларын һәм керем мөмкинлекләрен бәяләгәндәге аерманы исәпкә алып билгеләнә.

12. Шәһәр җирлекләренең (шәһәр округларын кертеп) бюджет тәэмин ителешен тигезләү критерие буларак билгеләнгән бюджет тәэмин ителеше дәрәҗәсенә шәһәр җирлеге (шәһәр округы) ирешү өчен җитми торган акчалар күләме бюджет тәэмин ителеше дәрәҗәсе шәһәр җирлекләренең (шәһәр округларын кертеп) бюджет тәэмин ителешен тигезләү критериеннан кимрәк булган шәһәр җирлекләре (шәһәр округларын кертеп) буенча гына исәпләнә:

$$\left(БО^i < К\right).$$

13. Шәһәр җирлекләре (шәһәр округларын кертеп) арасында бюджет тәэмин ителеше дәрәҗәсеннән чыгып бүленә торган ФФПГП акчаларының беренче өлешен бүлгәннән соң, шәһәр җирлекләренең (шәһәр округларын кертеп) ирешелгән бюджет тәэмин ителеше дәрәҗәсе билгеләнә, ул шәһәр җирлекләре (шәһәр округларын кертеп) арасында бюджет тәэмин ителеше дәрәҗәсеннән чыгып бүленә торган ФФПГП акчаларының икенче өлешен бүлгәндә кулланыла һәм түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$БО_1^i = БО_{расч}^i + \frac{Н^i \times SUM_{i=1}^n Ч^i}{ИБР^i \times Ч^i \times SUM_{i=1}^n УНП^i},$$

монда:

$БО_1^i$ – шәһәр җирлекләре (шәһәр округларын кертеп) арасында бюджет тәэмин ителеше дәрәҗәсеннән чыгып бүленә торган ФФПГП акчаларының беренче өлешен бүлгәннән соң i-шәһәр җирлегенең (шәһәр округының) бюджет тәэмин ителеше дәрәҗәсе;

$БО_{расч}^i$ – шәһәр җирлекләре (шәһәр округларын кертеп) арасында бюджет тәэмин ителеше дәрәҗәсеннән чыгып бүленә торган ФФПГП акчаларын бүлгәнгә кадәр i-шәһәр җирлегенең (шәһәр округының) бюджет тәэмин ителеше дәрәҗәсе;

$Н^i$ – i-шәһәр җирлегенә (шәһәр округына) беренче этапта бүленгән ФФПГП акчалары өлеше күләме;

$ИБР^i$ – i-шәһәр җирлегенең (шәһәр округының) әлеге Кодексның 6 нчы кушымтасында билгеләнгән тәртип нигезендә исәпләнә торган бюджет чыгымнары индексы;

$Ч^i$ – i-шәһәр җирлегенең (шәһәр округының) халык саны;

$УНП^i$ – i-шәһәр җирлегенең (шәһәр округының) әлеге Кодексның 7 нче кушымтасында билгеләнгән тәртип нигезендә исәпләнә торган шартлы салым потенциалы;

n – Татарстан Республикасындагы шәһәр җирлекләре (шәһәр округларын кертеп) саны.

14. Дотация өлешен “гарантияләнгән минимум”га кадәр тигезләү ысулын кулланып бүлү түбәндәге формула буенча башкарыла:

$$D_2^i = ИБР^i \times Ч^i x\left(БО - БО_1^i\right) \times \frac{SUM_{i=1}^n УНП^i}{SUM_{i=1}^n Ч^i},$$

монда:

$D_2^i$ – i-шәһәр җирлегенә (шәһәр округына) “гарантияләнгән минимум”га

кадәр тигезләү ысулы белән бүленә торган дотацияләр өлеше күләме;

БО – бюджет тәэмин ителешен тигезләү башкарыла торган минималь дәрәҗә;

$БО_1^i$ – шәһәр җирлекләре (шәһәр округларын кертеп) арасында бюджет тәэмин ителеше дәрәҗәсеннән чыгып бүленә торган ФФПГП акчаларының беренче өлешен бүлгәннән соң i-шәһәр җирлегенең (шәһәр округының) бюджет тәэмин ителеше дәрәҗәсе;

$ИБР^i$ – i-шәһәр җирлегенең (шәһәр округының) әлеге Кодексның 6 нчы кушымтасында билгеләнгән тәртип нигезендә исәпләнә торган бюджет чыгымнары индексы;

$Ч^i$ – i-шәһәр җирлегенең (шәһәр округының) халык саны;

$УНП^i$ – i-шәһәр җирлегенең (шәһәр округының) әлеге Кодексның 7 нче кушымтасында билгеләнгән тәртип нигезендә исәпләнә торган шартлы салым потенциалы;

n – Татарстан Республикасындагы шәһәр җирлекләре (шәһәр округларын кертеп) саны.

15. Шәһәр җирлегенең (шәһәр округларын кертеп) хисаплы бюджет тәэмин ителеше дәрәҗәсе барлык шәһәр җирлекләре (шәһәр округларын кертеп) буенча, бюджет хезмәт күрсәтүләре хакына йогынты ясый торган объектив факторларны һәм шартларны исәпкә алып, аның бер кешегә исәпләнгән шундый ук күрсәткечкә шартлы салым потенциалы чагыштырмасы буларак билгеләнә, ул түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$БО_{расч}^i = \frac{УНП^i \times SUM_{i=1}^{n} Ч^i}{ИБР^i \times Ч^i \times SUM_{i=1}^{n} УНП^i},$$

монда:

$БО_{расч}^i$ – i-шәһәр җирлегенең (шәһәр округының) хисаплы бюджет тәэмин ителеше дәрәҗәсе;

$ИБР^i$ – i-шәһәр җирлегенең (шәһәр округының) әлеге Кодексның 6 нчы кушымтасында билгеләнгән тәртип нигезендә исәпләнә торган бюджет чыгымнары индексы;

$УНП^i$– i-шәһәр җирлегенең (шәһәр округының) әлеге Кодексның 7 нче кушымтасында билгеләнгән тәртип нигезендә исәпләнә торган шартлы салым потенциалы;

$Ч^i$ – i-шәһәр җирлегенең (шәһәр округының) халык саны;

n – Татарстан Республикасындагы шәһәр җирлекләре (шәһәр округларын кертеп) саны.

16. Авыл җирлекләренең бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан j-авыл җирлеге өчен дотация күләме, халык санынннан чыгып, түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$ФП_{ффпсп}^j = V_{ффпсп} \times \frac{Ч_{сп}^j}{SUM_{j=1}^{s} Ч_{сп}^j},$$

монда:

$ФП^j_{ФФПСП}$ – авыл җирлекләренең бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан j-авыл җирлеге өчен, халык санынннан чыгып, дотация күләме;

$V_{ФФПСП}$ – халык санынннан чыгып, авыл җирлекләренең бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә ФФПСП күләме;

$Ч^j_{сп}$ – j-авыл җирлегенең халык саны;

s – Татарстан Республикасы бюджетыннан дотацияләр алу хокукына ия авыл җирлекләре саны.

17. Авыл җирлекләренең бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан дотация күләме, хисаплы бюджет тәэмин ителеше дәрәҗәсеннән чыгып, катнаш ысул белән билгеләнә. Дотацияләрнең беренче өлеше бюджет тәэмин ителешен пропорциональ тигезләү ысулын кулланып; дотацияләрнең икенче өлеше "гарантияләнгән минимум"га кадәр тигезләү ысулын кулланып бүленә:

$$D^i = D^i_1 + D^i_2 ,$$

монда:

$D^i$ – i-авыл җирлегенә, хисаплы бюджет тәэмин ителеше дәрәҗәсеннән чыгып, авыл җирлекләренең бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан дотациянең гомуми күләме;

$D^i_1$ – i-авыл җирлегенә пропорциональ тигезләү ысулы белән бүленә торган дотацияләр өлеше күләме;

$D^i_2$ – i-авыл җирлегенә "гарантияләнгән минимум"га кадәр тигезләү ысулы белән бүленә торган дотацияләр өлеше күләме.

18. Авыл җирлекләренең бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә хисаплы бюджет тәэмин ителеше дәрәҗәсеннән чыгып төрле ысуллар белән бүленә торган дотацияләрнең өлешләре арасындагы нисбәт ел саен чираттагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты проектын төзегәндә билгеләнә.

19. Дотацияләр өлешен бюджет тәэмин ителешен пропорциональ тигезләү ысулын кулланып бүлү түбәндәге формула буенча башкарыла:

$$D^i_1 = d_{ПП} \times V_{ФФПСП} \times \frac{H^i}{H} ,$$

монда:

$D^i_1$ – i-авыл җирлегенә пропорциональ тигезләү ысулы белән бүленә торган дотацияләр өлеше күләме;

$d_{ПП}$ – хисаплы бюджет тәэмин ителеше дәрәҗәсеннән чыгып, авыл җирлекләренең бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә пропорциональ тигезләү ысулын кулланып бүленә торган ФФПСП өлеше;

$V_{ФФПСП}$ – хисаплы бюджет тәэмин ителеше дәрәҗәсеннән чыгып, авыл җирлекләренең бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә ФФПСП күләме;

$Н^i$ – авыл җирлекләренең бюджет тәэмин ителешен тигезләү критерие буларак билгеләнгән бюджет тәэмин ителеше дәрәҗәсенә i-авыл җирлеге ирешү өчен кирәкле акчалар күләме;

Н – авыл җирлекләренең бюджет тәэмин ителешен тигезләү критерие буларак билгеләнгән бюджет тәэмин ителеше дәрәҗәсенә барлык авыл җирлекләре ирешү өчен кирәкле акчалар күләме.

20. Авыл җирлекләренең бюджет тәэмин ителешен тигезләү критерие буларак билгеләнгән бюджет тәэмин ителеше дәрәҗәсенә i-авыл җирлеге ирешү өчен кирәкле акчалар күләмен билгеләү түбәндәге формула буенча башкарыла:

$$Н^i = ИБР^i \times Ч^i \times \left(К - БО^i_{расч}\right) \times \frac{SUM^s_{i=1} УНП^i}{SUM^s_{i=1} Ч^i},$$

монда:

$Н^i$ – авыл җирлекләренең бюджет тәэмин ителешен тигезләү критерие буларак билгеләнгән бюджет тәэмин ителеше дәрәҗәсенә i-авыл җирлеге ирешү өчен кирәкле акчалар күләме;

$ИБР^i$ – i-авыл җирлегенең әлеге Кодексның 6 нчы кушымтасында билгеләнгән тәртип нигезендә исәпләнә торган бюджет чыгымнары индексы;

$Ч^i$ – i-авыл җирлегенең халык саны;

К – авыл җирлекләренең бюджет тәэмин ителешен тигезләү критерие;

$БО^i_{расч}$ – i-авыл җирлегенең хисаплы бюджет тәэмин ителеше дәрәҗәсе;

$УНП^i$ – i-авыл җирлегенең әлеге Кодексның 7 нче кушымтасында билгеләнгән тәртип нигезендә исәпләнә торган шартлы салым потенциалы;

s – Татарстан Республикасындагы авыл җирлекләре саны.

21. Авыл җирлекләренең хисаплы бюджет тәэмин ителешен тигезләү критерие ел саен чираттагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты проектын төзегәндә, муниципаль берәмлекләрнең суммар ихтыяҗларын һәм керем мөмкинлекләрен бәяләгәндәге аерманы исәпкә алып билгеләнә.

22. Авыл җирлекләренең бюджет тәэмин ителешен тигезләү критерие буларак билгеләнгән бюджет тәэмин ителеше дәрәҗәсенә авыл җирлеге ирешү өчен җитми торган акчалар күләме бюджет тәэмин ителеше дәрәҗәсе авыл җирлекләренең бюджет тәэмин ителешен тигезләү критериеннан кимрәк булган авыл җирлекләре буенча гына исәпләнә:

$$\left(БО^i < К\right).$$

23. Авыл җирлекләре арасында бюджет тәэмин ителеше дәрәҗәсеннән чыгып бүленә торган ФФПСП акчаларының беренче өлешен бүлгәннән соң,

авыл җирлекләренең ирешелгән бюджет тәэмин ителеше дәрәҗәсе билгеләнә, ул авыл җирлекләре арасында бюджет тәэмин ителеше дәрәҗәсеннән чыгып бүленә торган ФФПСП акчаларының икенче өлешен бүлгәндә кулланыла һәм түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$БО_1^i = БО_{расч}^i + \frac{H^i \times SUM_{i=1}^{s} Ч^i}{ИБР^i \times Ч^i \times SUM_{i=1}^{s} УНП^i},$$

монда:

$БО_1^i$ – авыл җирлекләре арасында бюджет тәэмин ителеше дәрәҗәсеннән чыгып бүленә торган ФФПСП акчаларының беренче өлешен бүлгәннән соң i-авыл җирлегенең бюджет тәэмин ителеше дәрәҗәсе;

$БО_{расч}^i$ – авыл җирлекләре арасында бюджет тәэмин ителеше дәрәҗәсеннән чыгып бүленә торган ФФПСП акчаларын бүлгәнгә кадәр i-авыл җирлегенең бюджет тәэмин ителеше дәрәҗәсе;

$H^i$ – i-авыл җирлегенә беренче этапта бүленгән ФФПСП акчалары өлеше күләме;

$ИБР^i$ – i-авыл җирлегенең әлеге Кодексның 6 нчы кушымтасында билгеләнгән тәртип нигезендә исәпләнә торган бюджет чыгымнары индексы;

$Ч^i$ – i-авыл җирлегенең халык саны;

$УНП^i$ – i-авыл җирлегенең әлеге Кодексның 7 нче кушымтасында билгеләнгән тәртип нигезендә исәпләнә торган шартлы салым потенциалы;

s – Татарстан Республикасындагы авыл җирлекләре саны.

24. Дотация өлешен “гарантияләнгән минимум”га кадәр тигезләү ысулын кулланып бүлү түбәндәге формула буенча башкарыла:

$$D_2^i = ИБР^i \times Ч^i \times (БО - БО_1^i) \times \frac{SUM_{i=1}^{s} УНП^i}{SUM_{i=1}^{s} Ч^i},$$

монда:

$D_2^i$ – i-авыл җирлегенә “гарантияләнгән минимум”га кадәр тигезләү ысулы белән бүленә торган дотацияләр өлеше күләме;

БО – бюджет тәэмин ителешен тигезләү башкарыла торган минималь дәрәҗә;

$БО_1^i$ – авыл җирлекләре арасында бюджет тәэмин ителеше дәрәҗәсеннән чыгып бүленә торган ФФПСП акчаларының беренче өлешен бүлгәннән соң i-авыл җирлегенең бюджет тәэмин ителеше дәрәҗәсе;

$ИБР^i$ – i-авыл җирлегенең әлеге Кодексның 6 нчы кушымтасында билгеләнгән тәртип нигезендә исәпләнә торган бюджет чыгымнары индексы;

$Ч^i$ – i-авыл җирлегендәге халык саны;

$УНП^i$ – i-авыл җирлегенең әлеге Кодексның 7 нче кушымтасында билгеләнгән тәртип нигезендә исәпләнә торган шартлы салым потенциалы;

s – Татарстан Республикасындагы авыл җирлекләре саны.

25. Авыл җирлегенең хисаплы бюджет тәэмин ителеше дәрәҗәсе барлык авыл җирлекләре буенча, бюджет хезмәт күрсәтүләре хакына йогынты ясый торган объектив факторларны һәм шартларны исәпкә алып, аның бер кешегә исәпләнгән шундый ук күрсәткечкә шартлы салым потенциалы чагыштырмасы буларак билгеләнә, ул түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$БО^{i}_{расч} = \frac{УНП^{i} \times SUM^{s}_{i=1}Ч^{i}}{ИБР^{i} \times Ч^{i} \times SUM^{s}_{i=1}УНП^{i}},$$

монда:

$БО^{i}_{расч}$ – i-авыл җирлегенең бюджет тәэмин ителеше дәрәҗәсе;

$ИБР^{i}$ – i-авыл җирлегенең әлеге Кодексның 6 нчы кушымтасында билгеләнгән тәртиптә исәпләнә торган бюджет чыгымнары индексы;

$УНП^{i}$ – i-авыл җирлегенең әлеге Кодексның 7 нче кушымтасында билгеләнгән тәртип нигезендә исәпләнә торган шартлы салым потенциалы;

$Ч^{i}$ – i-авыл җирлегенең халык саны;

s – Татарстан Республикасындагы авыл җирлекләре саны.”;

47) $2^{1}$ нче кушымтаның 2 пунктындагы дүртенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“$V_{дот}$ – муниципаль районнарның (шәһәр округларының) бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә дотацияләрне халык саныннан чыгып бирү өчен акчалар күләме;”;

48) 5 нче кушымтада:

а) исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

**“Муниципаль районнарның (шәһәр округларының) бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан дотацияләр бүлү методикасы”;**

б) 2 пунктта:

беренче абзацта “исәпләнә” сүзен “билгеләнә” сүзенә, “билгеләнә” сүзен “исәпләнә” сүзенә алмаштырырга;

бишенче абзацта “i-муниципаль районы” сүзләреннән соң “(шәһәр округы)” сүзләрен өстәргә;

сигезенче абзацта “Татарстан Республикасы бюджетыннан дотация алучы” сүзләрен “Татарстан Республикасындагы” сүзләренә алмаштырырга;

в) 3 пунктның дүртенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“$D^{i}$ – i-муниципаль районына (шәһәр округына), хисаплы бюджет тәэмин ителеше дәрәҗәсеннән чыгып, муниципаль районнарның (шәһәр округларының) бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан дотацияләрнең гомуми күләме;”;

г) 5 пунктның җиденче һәм сигезенче абзацларында “бюджет тәэмин ителешен тигезләү критерие” сүзләрен “муниципаль районнарның (шәһәр

округларының) хисаплы бюджет тәэмин ителешен тигезләү критерие” сүзләренә алмаштырырга;

д) 6 пунктта:

беренче һәм дүртенче абзацларда “бюджет тәэмин ителешен тигезләү критерие” сүзләрен “муниципаль районнарның (шәһәр округларының) хисаплы бюджет тәэмин ителешен тигезләү критерие” сүзләренә алмаштырырга;

алтынчы абзацта “i-муниципаль берәмлек” сүзләрен “i-муниципаль районы (шәһәр округы)” сүзләренә алмаштырырга;

җиденче абзацта “бюджет тәэмин ителешен” сүзләрен “муниципаль районнарның (шәһәр округларының) хисаплы бюджет тәэмин ителешен” сүзләренә алмаштырырга;

унынчы абзацта “Татарстан Республикасы бюджетыннан дотация ала торган” сүзләрен “Татарстан Республикасындагы” сүзләренә алмаштырырга;

е) 8 пунктның беренче абзацында “бюджет тәэмин ителешен тигезләү критерие” сүзләрен “муниципаль районнарның (шәһәр округларының) хисаплы бюджет тәэмин ителешен тигезләү критерие” сүзләренә алмаштырырга;

ж) 9 пунктта:

сигезенче абзацта “i-муниципаль берәмлек” сүзләрен “i-муниципаль районы (шәһәр округы)” сүзләренә алмаштырырга;

унынчы абзацта “Татарстан Республикасы бюджетыннан дотация ала торган” сүзләрен “Татарстан Республикасындагы” сүзләренә алмаштырырга;

з) 10 пунктның унынчы абзацында “Татарстан Республикасы бюджетыннан дотация ала торган” сүзләрен “Татарстан Республикасындагы” сүзләренә алмаштырырга;

49) $9^3$ нче кушымтада:

а) исемендә “муниципаль берәмлекләр бюджетларына” сүзләрен “муниципаль районнар һәм шәһәр округлары бюджетларына” сүзләренә алмаштырырга;

б) 1 пунктта “муниципаль берәмлекләр арасында” сүзләрен “муниципаль районнар һәм шәһәр округлары бюджетларына” сүзләренә алмаштырырга;

в) 2 пунктта:

беренче абзацта “муниципаль берәмлекләр бюджетларына” сүзләрен “тиешле муниципаль район, шәһәр округы бюджетына (алга таба – i-муниципаль берәмлеге)” сүзләренә алмаштырырга;

сигезенче абзацта “муниципаль берәмлекнең” сүзләрен “i-муниципаль берәмлегенең” сүзләренә алмаштырырга;

унөченче абзацта “муниципаль берәмлекнең” сүзләрен “i-муниципаль берәмлегенең” сүзләренә алмаштырырга;

утыз бишенче абзацта “муниципаль берәмлекләр арасында” сүзләрен “муниципаль районнар һәм шәһәр округлары арасында” сүзләренә алмаштырырга;

кырыгынчы абзацта “барлык муниципаль берәмлекләр буенча” сүзләрен “барлык муниципаль районнар һәм шәһәр округлары буенча” сүзләренә алмаштырырга;

50) 12 нче кушымтада:

а) исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Җирлекләрнең бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә муниципаль район бюджетыннан дотацияләр бүлү тәртибе”;

б) 1 пунктның икенче абзацында “җирлекләр” сүзен “шәһәр, авыл җирлекләре” сүзләренә, “муниципаль райондагы җирлекләрнең исәпләп чыгарылган дәрәҗәсен һәм барлык җирлекләр буенча шундый ук уртача күрсәткечне чагыштыру нигезендә” сүзләрен “шәһәр һәм авыл җирлекләренең хисаплы бюджет тәэмин ителеше дәрәҗәсен чагыштыру нигезендә” сүзләренә алмаштырырга;

в) 2 пунктның беренче абзацындагы беренче җөмләдә “Җирлекнең” сүзен “Шәһәр, авыл җирлегенең” сүзләренә, “барлык җирлекләр буенча” сүзләрен “барлык шәһәр, авыл җирлекләре буенча” сүзләренә алмаштырырга, “һәм шәһәр, авыл җирлекләре өчен аерым билгеләнергә мөмкин” сүзләрен өстәргә;

г) 4 пунктның дүртенче абзацында “дотацияләрнең” сүзләренә кадәр “җирлекләрнең бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә” сүзләрен өстәргә;

д) 6 пунктның җиденче һәм сигезенче абзацларында “бюджет тәэмин ителешен” сүзләренә кадәр “җирлекләрнең” сүзен өстәргә;

е) 7 пунктта:

беренче һәм дүртенче абзацларда “бюджет тәэмин ителешен тигезләү критерие буларак” сүзләренә кадәр “җирлекләрнең” сүзен өстәргә;

алтынчы абзацта “j-муниципаль берәмлегенең” сүзләрен “j-җирлегенең” сүзләренә алмаштырырга;

җиденче абзацта “бюджеттан тәэмин ителешне” сүзләрен “җирлекләрнең бюджеттан тәэмин ителешен” сүзләренә алмаштырырга;

унынчы абзацта “бюджетыннан дотация алучы җирлекләр” сүзләрен “җирлекләре” сүзенә алмаштырырга;

ж) 9 пунктта “бюджет тәэмин ителешен тигезләү критерие” сүзләрен “җирлекләрнең бюджет тәэмин ителешен тигезләү критерие” сүзләренә алмаштырырга;

з) 10 пунктның унынчы абзацында “бюджетыннан дотация алучы җирлекләр” сүзләрен “җирлекләре” сүзенә алмаштырырга;

и) 11 пунктның унынчы абзацында “бюджетыннан дотация алучы җирлекләр” сүзләрен “җирлекләре” сүзенә алмаштырырга.

**2 статья**

“Муниципаль районнарның җирле үзидарә органнарына җирлекләрнең региональ финанс ярдәме фондыннан җирлекләргә дотацияләр исәпләү һәм бирү буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен тапшыру турында” 2005

елның 22 декабрендәге 132-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2005, № 12 (II өлеш); 2009, № 7 – 8 (I өлеш); 2010, № 7 (II өлеш); 2013, № 10) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) исемендә "җирлекләргә" сүзен "шәһәр, авыл җирлекләре бюджетларына" сүзләренә алмаштырырга;

2) 1 статьяда "җирлекләргә" сүзен "шәһәр, авыл җирлекләре бюджетларына" сүзләренә алмаштырырга;

3) 5 статьяның 2 пунктында "җирлекләргә" сүзен "шәһәр, авыл җирлекләре бюджетларына" сүзләренә алмаштырырга;

4) 1 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Муниципаль районнарның җирле үзидарә органнарына җирлекләрнең региональ финанс ярдәме фондыннан шәһәр, авыл җирлекләре бюджетларына дотацияләр исәпләү һәм бирү буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен тапшыру турында" Татарстан Республикасы Законына
1 нче кушымта

**ШӘҺӘР, АВЫЛ ҖИРЛЕКЛӘРЕ БЮДЖЕТЛАРЫНА ДОТАЦИЯЛӘР ИСӘПЛӘҮ ҺӘМ БИРҮ ВӘКАЛӘТЛӘРЕН ГАМӘЛГӘ АШЫРУГА ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БЮДЖЕТЫННАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОННАР БЮДЖЕТЛАРЫНА СУБВЕНЦИЯЛӘР ИСӘПЛӘҮ МЕТОДИКАСЫ**

1. Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән шәһәр, авыл җирлекләре бюджетларына дотацияләр исәпләү һәм бирү вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга Татарстан Республикасы бюджетыннан муниципаль районнар бюджетларына субвенцияләр күләме ел саен чираттагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты проектын төзегәндә билгеләнә.

2. Субвенцияләр муниципаль районнар арасында, муниципаль районның халык саныннан чыгып, Татарстан Республикасы Бюджет кодексының $44^{10}$ статьясында билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы бюджетына үз бюджетларыннан субсидияләр күчерә торган шәһәр, авыл җирлекләреннән тыш, бер кеше исәбеннән бүленә.

3. Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән муниципаль районның шәһәр, авыл җирлекләре бюджетларына дотацияләр исәпләү һәм бирү вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга Татарстан Республикасы бюджетыннан i-муниципаль районы бюджетына субвенция күләме түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$V^{i}_{МБР} = V^{i}_{МБРГП} + V^{i}_{МБРСП},$$

монда:

$V^{i}_{МБР}$ – Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән шәһәр, авыл җирлекләре бюджетларына дотацияләр исәпләү һәм бирү вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга Татарстан Республикасы бюджетыннан i-муниципаль районы бюджетына субвенциянең гомуми күләме;

$V^{i}_{МБРГП}$ – Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән шәһәр, авыл җирлекләре бюджетларына дотацияләр исәпләү һәм бирү вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга Татарстан Республикасы бюджетыннан i-муниципаль районы бюджетына шәһәр җирлекләре бюджетларына бирү өчен билгеләнгән субвенция өлеше күләме;

$V^{i}_{МБРСП}$ – Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән шәһәр, авыл җирлекләре бюджетларына дотацияләр исәпләү һәм бирү вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга Татарстан Республикасы бюджетыннан i-муниципаль районы бюджетына авыл җирлекләре бюджетларына бирү өчен билгеләнгән субвенция өлеше күләме.

4. Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән шәһәр, авыл җирлекләре бюджетларына дотацияләр исәпләү һәм бирү вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга Татарстан Республикасы бюджетыннан i-муниципаль районы бюджетына шәһәр җирлекләре бюджетларына бирү өчен билгеләнгән субвенция өлеше күләме түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$V^{i}_{МБРГП} = V_{МБРГП} \times \frac{SUM^{n}_{j=1} Ч^{i}_{ГПj}}{SUM^{m}_{i=1} SUM^{n}_{j=1} Ч^{i}_{ГПj}},$$

монда:

$V^{i}_{МБРГП}$ – Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән шәһәр, авыл җирлекләре бюджетларына дотацияләр исәпләү һәм бирү вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга Татарстан Республикасы бюджетыннан i-муниципаль районы бюджетына шәһәр җирлекләре бюджетларына бирү өчен билгеләнгән субвенция өлеше күләме;

$V_{МБРГП}$ – Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән шәһәр, авыл җирлекләре бюджетларына дотацияләр исәпләү һәм бирү вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга Татарстан Республикасы бюджетыннан муниципаль районнар бюджетларына шәһәр җирлекләре бюджетларына бирү өчен билгеләнгән субвенцияләрнең гомуми күләме;

$Ч^{i}_{гпj}$ – i-муниципаль районының j-шәһәр җирлегендәге халык саны;

m – Татарстан Республикасының муниципаль районнары саны;

n – i-муниципаль районы составына керүче шәһәр җирлекләре саны, бюджетларыннан Татарстан Республикасы Бюджет кодексының $44^{10}$ статьясы белән билгеләнгән тәртип нигезендә Татарстан Республикасы бюджетына субсидияләр күчерелә торган шәһәр җирлекләреннән тыш.

5. Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән шәһәр, авыл җирлекләре бюджетларына дотацияләрне исәпләү һәм бирү буенча вәкаләтләрне гамәлгә ашыруга Татарстан Республикасы бюджетыннан i-муниципаль районы бюджетына авыл җирлекләре бюджетларына бирү өчен билгеләнгән субвенция өлеше күләме түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$V^{i}_{МБРСП} = V_{МБРСП} \times \frac{SUM^{s}_{j=1} Ч^{i}_{СПj}}{SUM^{m}_{i=1} SUM^{s}_{j=1} Ч^{i}_{СПj}},$$

монда:

$V^{i}_{МБРСП}$ – Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән шәһәр, авыл җирлекләре бюджетларына дотацияләрне исәпләү һәм бирү буенча вәкаләтләрне гамәлгә ашыруга Татарстан Республикасы бюджетыннан i-муниципаль районы бюджетына авыл җирлекләре бюджетларына бирү өчен билгеләнгән субвенция өлеше күләме;

$V_{МБРСП}$ – Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән шәһәр, авыл җирлекләре бюджетларына дотацияләрне исәпләү һәм бирү буенча вәкаләтләрне гамәлгә ашыруга Татарстан Республикасы бюджетыннан муниципаль районнар бюджетларына авыл җирлекләре бюджетларына бирү өчен билгеләнгән субвенцияләрнең гомуми күләме;

$Ч^{i}_{спj}$ – i-муниципаль районының j-авыл җирлегендәге халык саны;

m – Татарстан Республикасының муниципаль районнары саны;

s – i-муниципаль районы составына керүче авыл җирлекләре саны, бюджетларыннан Татарстан Республикасы Бюджет кодексының $44^{10}$ статьясы белән билгеләнгән тәртип нигезендә Татарстан Республикасы бюджетына субсидияләр күчерелә торган авыл җирлекләреннән тыш.”;

5) 2 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Муниципаль районнарның җирле үзидарә органнарына җирлекләрнең региональ финанс ярдәме фондыннан шәһәр, авыл җирлекләре бюджетларына дотацияләр исәпләү һәм бирү буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен тапшыру турында” Татарстан Республикасы Законына
2 нче кушымта

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БЮДЖЕТЫННАН СУБВЕНЦИЯЛӘР ИСӘБЕННӘН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОННАРНЫҢ ҖИРЛЕ ҮЗИДАРӘ ОРГАННАРЫ ТАРАФЫННАН ШӘҺӘР, АВЫЛ ҖИРЛЕКЛӘРЕ БЮДЖЕТЛАРЫНА ДОТАЦИЯЛӘР КҮЛӘМЕН ИСӘПЛӘҮ МЕТОДИКАСЫ, ШУЛ ИСӘПТӘН ФИЗИК ЗАТЛАР КЕРЕМНӘРЕНӘ САЛЫМНАН АЛЫНА ТОРГАН ТҮЛӘҮЛӘРНЕҢ ӘЛЕГЕ ДОТАЦИЯЛӘРНЕ АЛМАШТЫРУЧЫ ӨСТӘМӘ НОРМАТИВЛАРЫН ИСӘПЛӘҮ ТӘРТИБЕ

1. Муниципаль районнарның җирле үзидарә органнары Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән шәһәр, авыл җирлекләре бюджетларына дотацияләр исәпләү һәм бирү буенча вәкаләтләрне башкаруга җирлекләргә район финанс ярдәме фондына (алга таба – РФПГП) керүче шәһәр җирлекләре бюджетларына бирү өчен билгеләнә торган Татарстан Республикасы бюджетыннан субвенцияләр өлеше исәбеннән шәһәр җирлекләре бюджетларына дотацияләрне әлеге методиканың 2 – 9 пунктлары нигезендә бүлә, бу очракта шәһәр җирлекләре бюджетлары арасында төрле ысуллар белән бүленә торган акча өлешләре арасында нисбәт ел саен чираттагы финанс елына (чираттагы финанс елына һәм план чорына) муниципаль район бюджеты төзегәндә билгеләнә.

Муниципаль районнарның җирле үзидарә органнары Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән шәһәр, авыл җирлекләре бюджетларына дотацияләр исәпләү һәм бирү буенча вәкаләтләрне башкаруга җирлекләргә район финанс ярдәме фондына (алга таба – РФПСП) керүче авыл җирлекләре бюджетларына бирү өчен билгеләнә торган Татарстан Республикасы бюджетыннан субвенцияләр өлеше исәбеннән авыл җирлекләре бюджетларына дотацияләрне әлеге методиканың 10 – 17 пунктлары нигезендә бүлә, бу очракта авыл җирлекләре бюджетлары арасында төрле ысуллар белән бүленә торган акча өлешләре арасында нисбәт ел саен чираттагы финанс елына (чираттагы финанс елына һәм план чорына) муниципаль район бюджеты төзегәндә билгеләнә.

2. Халык саныннан чыгып, i-муниципаль районының j-шәһәр җирлегенә дотация күләме түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$ФП^{j}_{ГП} = V^{i}_{РФПГПЧ} \times \frac{Ч^{j}_{ГП}}{SUM^{n}_{j=1} Ч^{i}_{ГП}},$$

монда:

$ФП^{j}_{ГП}$ – халык саныннан чыгып, j-шәһәр җирлегенә РФПГПдан дотация күләме;

$V^{i}_{РФПГПЧ}$ – халык саныннан чыгып бүленә торган РФПГП күләме;

$Ч^{j}_{ГП}$ – j-шәһәр җирлегенең халык саны;

n – i-муниципаль районы составына керүче шәһәр җирлекләре саны,

бюджетларыннан Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 44[10] статьясы белән билгеләнгән тәртип нигезендә Татарстан Республикасы бюджетына субсидияләр күчерелә торган шәһәр җирлекләреннән тыш.

3. Шәһәр җирлекләренең бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә РФПГПдан шәһәр җирлекләренә дотация күләме, хисаплы бюджет тәэмин ителеше дәрәҗәсеннән чыгып, катнаш ысул белән билгеләнә. Дотацияләрнең беренче өлеше – бюджет тәэмин ителешен пропорциональ тигезләү ысулын кулланып; дотацияләрнең икенче өлеше "гарантияләнгән минимум"га кадәр тигезләү ысулын кулланып бүленә:

$$D^i = D^i_1 + D^i_2 ,$$

монда:

$D^i$ – i-шәһәр җирлеге өчен, хисаплы бюджет тәэмин ителеше дәрәҗәсеннән чыгып, шәһәр җирлекләренең бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә РФПГПдан дотациянең гомуми күләме;

$D^i_1$ – i-шәһәр җирлегенә пропорциональ тигезләү ысулы белән бүленә торган дотацияләр өлеше күләме;

$D^i_2$ – i-шәһәр җирлегенә "гарантияләнгән минимум"га кадәр тигезләү ысулы белән бүленә торган дотацияләр өлеше күләме.

4. Дотацияләр өлешен бюджет тәэмин ителешен пропорциональ тигезләү ысулын кулланып бүлү түбәндәге формула буенча башкарыла:

$$D^i_1 = d_{ПП} \times V_{РФПГП} \times \frac{H^i}{H} ,$$

монда:

$D^i_1$ – i-шәһәр җирлегенә пропорциональ тигезләү ысулы белән бүленә торган дотацияләр өлеше күләме;

$d_{ПП}$ – хисаплы бюджет тәэмин ителеше дәрәҗәсеннән чыгып, шәһәр җирлекләренең бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә пропорциональ тигезләү ысулын кулланып бүленә торган РФПГП өлеше;

$V_{РФПГП}$ – хисаплы бюджет тәэмин ителеше дәрәҗәсеннән чыгып, шәһәр җирлекләренең бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә РФПГП күләме;

$H^i$ – шәһәр җирлекләренең бюджет тәэмин ителешен тигезләү критерие буларак билгеләнгән бюджет тәэмин ителеше дәрәҗәсенә i-шәһәр җирлеге ирешү өчен кирәкле акчалар күләме;

$H$ – бөтен шәһәр җирлекләренә бюджет тәэмин ителешенең шәһәр җирлекләренең бюджет тәэмин ителешен тигезләү критерие буларак билгеләнгән дәрәҗәсенә ирешү өчен кирәкле акчалар күләме.

5. Шәһәр җирлекләренең бюджет тәэмин ителешен тигезләү критерие буларак билгеләнгән бюджет тәэмин ителеше дәрәҗәсенә i-шәһәр җирлеге ирешү өчен кирәкле акчалар күләмен билгеләү түбәндәге формула буенча башкарыла:

$$H^i = ИБР^i \times Ч^i \times \left(К - БО^i_{расч}\right) \times \frac{SUM^n_{i=1} УНП^i}{SUM^n_{i=1} Ч^i} ,$$

монда:

$Н^{i}$ – шәһәр җирлекләренең бюджет тәэмин ителешен тигезләү критерие буларак билгеләнгән бюджет тәэмин ителеше дәрәҗәсенә i-шәһәр җирлегенә ирешү өчен кирәкле акчалар күләме;

$ИБР^{i}$ – i-шәһәр җирлегенең Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 6 нчы кушымтасында билгеләнгән тәртип нигезендә исәпләнә торган бюджет чыгымнары индексы;

$Ч^{i}$ – i-шәһәр җирлегенең халык саны;

К – шәһәр җирлекләренең бюджет тәэмин ителешен тигезләү критерие;

$БО^{i}_{расч.}$ – i-шәһәр җирлегенең хисаплы бюджет тәэмин ителеше дәрәҗәсе;

$УНП^{i}$ – i-шәһәр җирлегенең Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 7 нче кушымтасында билгеләнгән тәртип нигезендә исәпләнә торган шартлы салым потенциалы;

n – муниципаль районның шәһәр җирлекләре саны.

6. Шәһәр җирлекләренең бюджет тәэмин ителешен тигезләү критерие буларак билгеләнгән бюджет тәэмин ителеше дәрәҗәсенә i-шәһәр җирлеге ирешү өчен җитми торган акчалар күләме бюджет тәэмин ителеше дәрәҗәсе шәһәр җирлекләренең бюджет тәэмин ителешен тигезләү критерийеннан кимрәк булган шәһәр җирлекләре буенча гына исәпләнә:

$$\left(БО^{i} < К\right).$$

7. Шәһәр җирлекләре арасында бюджет тәэмин ителеше дәрәҗәсеннән чыгып бүленә торган РФПГП акчаларының беренче өлешен бүлгәннән соң шәһәр җирлекләренең ирешелгән бюджет тәэмин ителеше дәрәҗәсе билгеләнә, ул шәһәр җирлекләре арасында бюджет тәэмин ителеше дәрәҗәсеннән чыгып бүленә торган РФПГП акчаларының икенче өлешен бүлгәндә кулланыла һәм түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$БО^{i}_{1} = БО^{i}_{расч} + \frac{Н^{i} \times SUM^{n}_{i=1}Ч^{i}}{ИБР^{i} \times Ч^{i} \times SUM^{n}_{i=1}УНП^{i}},$$

монда:

$БО^{i}_{1}$ – шәһәр җирлекләре арасында бюджет тәэмин ителеше дәрәҗәсеннән чыгып бүленә торган РФПГП акчаларының беренче өлешен бүлгәннән соң i-шәһәр җирлегенең бюджет тәэмин ителеше дәрәҗәсе;

$БО^{i}_{расч}$ – шәһәр җирлекләре арасында бюджет тәэмин ителеше дәрәҗәсеннән чыгып бүленә торган РФПГП акчаларын бүлгәнгә кадәр i-шәһәр җирлегенең бюджет тәэмин ителеше дәрәҗәсе;

$Н^{i}$ – i-шәһәр җирлегенә беренче этапта бүленгән РФПГП өлеше күләме;

$ИБР^{i}$ – i-шәһәр җирлегенең Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 6 нчы кушымтасында билгеләнгән тәртип нигезендә исәпләнә торган бюджет чыгымнары индексы;

$Ч^{i}$ – i-шәһәр җирлегенең халык саны;

$УНП^{i}$ – i-шәһәр җирлегенең Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 7 нче кушымтасында билгеләнгән тәртип нигезендә исәпләнә торган шартлы салым потенциалы;

n – муниципаль районның шәһәр җирлекләре саны.

8. Дотацияләр өлешен "гарантияләнгән минимум"га кадәр тигезләү ысулын кулланып бүлү түбәндәге формула буенча башкарыла:

$$D_2^i = ИБР^i \times Ч^i \times (БО - БО_1^i) \times \frac{SUM_{i=1}^n УНП^i}{SUM_{i=1}^n Ч^i},$$

монда:

$D^i_2$ – i-шәһәр җирлегенә "гарантияләнгән минимумга кадәр" тигезләү ысулы белән бүленә торган дотацияләр өлеше күләме;

БО – бюджет тәэмин ителешен тигезләү башкарыла торган минималь дәрәҗә;

$БО^i_1$ – шәһәр җирлекләре арасында бюджет тәэмин ителеше дәрәҗәсеннән чыгып бүленә торган РФПГП акчаларының беренче өлешен бүлгәннән соң i-шәһәр җирлегенең бюджет тәэмин ителеше дәрәҗәсе;

$ИБР^i$ – i-шәһәр җирлегенең Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 6 нчы кушымтасында билгеләнгән тәртип нигезендә исәпләнә торган бюджет чыгымнары индексы;

$Ч^i$ – i-шәһәр җирлегенең халык саны;

$УНП_i$ – i-шәһәр җирлегенең Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 7 нче кушымтасында билгеләнгән тәртип нигезендә исәпләнә торган шартлы салым потенциалы;

n – муниципаль районның шәһәр җирлекләре саны.

9. Шәһәр җирлегенең хисаплы бюджет тәэмин ителеше дәрәҗәсе барлык шәһәр җирлекләре буенча, бюджет хезмәт күрсәтүләре хакына йогынты ясый торган объектив факторларны һәм шартларны исәпкә алып, аның бер кешегә исәпләнгән шундый ук күрсәткечкә шартлы салым потенциалы чагыштырмасы буларак билгеләнә, ул түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$БО^i_{расч} = \frac{УНП^i \times SUM_{i=1}^n Ч^i}{ИБР^i \times Ч^i \times SUM_{i=1}^n УНП^i},$$

монда:

$БО^i_{расч.}$ – i-шәһәр җирлегенең хисаплы бюджет тәэмин ителеше дәрәҗәсе;

$ИБР^i$ – i-шәһәр җирлегенең Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 6 нчы кушымтасында билгеләнгән тәртип нигезендә исәпләнә торган бюджет чыгымнары индексы;

$УНП_i$ – i-шәһәр җирлегенең Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 7 нче кушымтасында билгеләнгән тәртип нигезендә исәпләнә торган шартлы салым потенциалы;

$Ч^i$ – i-шәһәр җирлегенең халык саны;

n – муниципаль районның шәһәр җирлекләре саны.

10. Халык саныннан чыгып, i-муниципаль районының j-авыл җирлегенә дотация күләме түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$ФП^{j}_{СП} = V^{i}_{РФПСПЧ} \times \frac{Ч^{j}_{СП}}{SUM^{s}_{j=1} Ч^{j}_{СП}},$$

монда:

$ФП^{j}_{СП}$ – халык санынннан чыгып, j-шәһәр җирлегенә РФПСПдан дотация күләме;

$V^{i}_{РФПСПЧ}$ – халык санынннан чыгып бүленә торган РФПСП күләме;

$Ч^{j}_{ГП}$ – j-авыл җирлегендәге халык саны;

s – i-муниципаль районы составына керүче авыл җирлекләре саны, бюджетларыннан Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 44[10] статьясы белән билгеләнгән тәртип нигезендә Татарстан Республикасы бюджетына субсидияләр күчерелә торган авыл җирлекләреннән тыш.

11. Авыл җирлекләренең бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә РФПСПдан авыл җирлекләренә дотация күләме, хисаплы бюджет тәэмин ителеше дәрәҗәсеннән чыгып, катнаш ысул белән билгеләнә. Дотацияләрнең беренче өлеше – бюджет тәэмин ителешен пропорциональ тигезләү ысулын кулланып; дотацияләрнең икенче өлеше "гарантияләнгән минимум"га кадәр тигезләү ысулын кулланып бүленә:

$$D^{i} = D^{i}_{1} + D^{i}_{2},$$

монда:

$D^{i}$ – i-авыл җирлегенә, хисаплы бюджет тәэмин ителеше дәрәҗәсеннән чыгып, авыл җирлекләренең бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә РФПГПдан дотациянең гомуми күләме;

$D^{i}_{1}$ – i-авыл җирлегенә пропорциональ тигезләү ысулы белән бүленә торган дотацияләр өлеше күләме;

$D^{i}_{2}$ – i-авыл җирлегенә "гарантияләнгән минимум"га кадәр тигезләү ысулы белән бүленә торган дотацияләр өлеше күләме.

12. Дотацияләр өлешен бюджет тәэмин ителешен пропорциональ тигезләү ысулын кулланып бүлү түбәндәге формула буенча башкарыла:

$$D^{i}_{1} = d_{ПП} \times V_{РФПСП} \times \frac{H^{i}}{H},$$

монда:

$D^{i}_{1}$ – i-авыл җирлегенә пропорциональ тигезләү ысулы белән бүленә торган дотацияләр өлеше күләме;

$d_{ПП}$ – хисаплы бюджет тәэмин ителеше дәрәҗәсеннән чыгып, авыл җирлекләренең бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә пропорциональ тигезләү ысулын кулланып бүленә торган РФПСП өлеше;

$V_{РФПСП}$ – хисаплы бюджет тәэмин ителеше дәрәҗәсеннән чыгып, авыл җирлекләренең бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә РФПСП күләме;

$H^{i}$ – i-авыл җирлегенә бюджет тәэмин ителешенең авыл җирлекләренең бюджет тәэмин ителешен тигезләү критерие буларак билгеләнгән дәрәҗәсенә ирешү өчен кирәкле акчалар күләме;

Н – авыл җирлекләренең бюджет тәэмин ителешен тигезләү критерие буларак билгеләнгән бюджет тәэмин ителеше дәрәҗәсенә бөтен авыл җирлекләре ирешү өчен кирәкле акчалар күләме.

13. Авыл җирлекләренең бюджет тәэмин ителешен тигезләү критерие буларак билгеләнгән бюджет тәэмин ителеше дәрәҗәсенә i-авыл җирлеге ирешү өчен кирәкле акчалар күләмен билгеләү түбәндәге формула буенча башкарыла:

$$Н^i = ИБР^i \times Ч^i \times \left(К - БО^i_{расч}\right) \times \frac{SUM^s_{i=1} УНП^i}{SUM^s_{i=1} Ч^i},$$

монда:

$Н^i$ – авыл җирлекләренең бюджет тәэмин ителешен тигезләү критерие буларак билгеләнгән бюджет тәэмин ителеше дәрәҗәсенә i-авыл җирлегенә ирешү өчен кирәкле акчалар күләме;

$ИБР^i$ – i-авыл җирлегенең Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 6 нчы кушымтасында билгеләнгән тәртип нигезендә исәпләнә торган бюджет чыгымнары индексы;

$Ч^i$ – i-авыл җирлегенең халык саны;

К – авыл җирлекләренең бюджет тәэмин ителешен тигезләү критерие;

$БО^i_{расч.}$ – i-авыл җирлегенең хисаплы бюджет тәэмин ителеше дәрәҗәсе;

$УНП^i$ – i-авыл җирлегенең Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 7 нче кушымтасында билгеләнгән тәртип нигезендә исәпләнә торган шартлы салым потенциалы;

s – муниципаль районның авыл җирлекләре саны.

14. Авыл җирлекләренең бюджет тәэмин ителешен тигезләү критерие буларак билгеләнгән бюджет тәэмин ителеше дәрәҗәсенә i-авыл җирлеге ирешү өчен җитми торган акчалар күләме бюджет тәэмин ителеше дәрәҗәсе авыл җирлекләренең бюджет тәэмин ителешен тигезләү критериеннан кимрәк булган авыл җирлекләре буенча гына исәпләнә:

$$\left(БО^i < К\right).$$

15. Авыл җирлекләре арасында бюджет тәэмин ителеше дәрәҗәсеннән чыгып бүленә торган РФПСП акчаларының беренче өлешен бүлгәннән соң авыл җирлекләренең ирешелгән бюджет тәэмин ителеше дәрәҗәсе билгеләнә, ул авыл җирлекләре арасында бюджет тәэмин ителеше дәрәҗәсеннән чыгып бүленә торган РФПСП акчаларының икенче өлешен бүлгәндә кулланыла һәм түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$БО^i_1 = БО^i_{расч} + \frac{Н^i \times SUM^s_{i=1} Ч^i}{ИБР^i \times Ч^i \times SUM^s_{i=1} УНП^i},$$

монда:

$БО^i_1$ – авыл җирлекләре арасында бюджет тәэмин ителеше дәрәҗәсеннән чыгып бүленә торган РФПСП акчаларының беренче өлешен бүлгәннән соң i-авыл җирлегенең бюджет тәэмин ителеше дәрәҗәсе;

$БО^{i}_{расч}$ – авыл җирлекләре арасында бюджет тәэмин ителеше дәрәҗәсеннән чыгып бүленә торган РФПСП акчаларын бүлгәнгә кадәр i-авыл җирлегенең бюджет тәэмин ителеше дәрәҗәсе;

$Н^{i}$ – i-авыл җирлегенә беренче этапта бүленгән РФПСП акчалары өлеше күләме;

$ИБР^{i}$ – i-авыл җирлегенең Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 6 нчы кушымтасында билгеләнгән тәртип нигезендә исәпләнә торган бюджет чыгымнары индексы;

$Ч^{i}$ – i-авыл җирлегенең халык саны;

$УНП^{i}$ – i-авыл җирлегенең Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 7 нче кушымтасында билгеләнгән тәртип нигезендә исәпләнә торган шартлы салым потенциалы;

s – муниципаль районның авыл җирлекләре саны.

16. Дотацияләр өлешен "гарантияләнгән минимум"га кадәр тигезләү ысулын кулланып бүлү түбәндәге формула буенча башкарыла:

$$D^{i}_{2} = ИБР^{i} \times Ч^{i} x \left(БО - БО^{i}_{1}\right) \times \frac{SUM^{s}_{i=1} УНП^{i}}{SUM^{s}_{i=1} Ч^{i}},$$

монда:

$D^{i}_{2}$ – i-авыл җирлегенә "гарантияләнгән минимумга" кадәр тигезләү ысулы белән бүленә торган дотацияләр өлеше күләме;

БО – бюджет тәэмин ителешен тигезләү башкарыла торган минималь дәрәҗә;

$БО^{i}_{1}$ – авыл җирлекләре арасында бюджет тәэмин ителеше дәрәҗәсеннән чыгып бүленә торган РФПСП акчаларының беренче өлешен бүлгәннән соң i-авыл җирлегенең бюджет тәэмин ителеше дәрәҗәсе;

$ИБР^{i}$ – i-авыл җирлегенең Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 6 нчы кушымтасында билгеләнгән тәртип нигезендә исәпләнә торган бюджет чыгымнары индексы;

$Ч^{i}$ – i-авыл җирлегенең халык саны;

$УНП_{i}$ – i-авыл җирлегенең Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 7 нче кушымтасында билгеләнгән тәртип нигезендә исәпләнә торган шартлы салым потенциалы;

s – муниципаль районның авыл җирлекләре саны.

17. Авыл җирлегенең хисаплы бюджет тәэмин ителеше дәрәҗәсе барлык авыл җирлекләре буенча, бюджет хезмәт күрсәтүләре хакына йогынты ясый торган объектив факторларны һәм шартларны исәпкә алып, аның бер кешегә исәпләнгән шундый ук күрсәткечкә шартлы салым потенциалы чагыштырмасы буларак билгеләнә, ул түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$БО^{i}_{расч} = \frac{УНП^{i} \times SUM^{s}_{i=1} Ч^{i}}{ИБР^{i} \times Ч^{i} \times SUM^{s}_{i=1} УНП^{i}},$$

монда:

$БО^{i}_{расч.}$ – i-авыл җирлегенең хисаплы бюджет тәэмин ителеше дәрәҗәсе;

$ИБР^i$ – i-авыл җирлегенең Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 6 нчы кушымтасында билгеләнгән тәртип нигезендә исәпләнә торган бюджет чыгымнары индексы;

$УНП_i$ – i-авыл җирлегенең Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 7 нче кушымтасында билгеләнгән тәртип нигезендә исәпләнә торган шартлы салым потенциалы;

$Ч^i$ – i-авыл җирлегенең халык саны;

s – муниципаль районның авыл җирлекләре саны.

18. Татарстан Республикасы бюджетыннан субвенцияләр исәбеннән шәһәр, авыл җирлекләренә дотацияләр физик затлар керемнәренә салымнан алына торган түләүләрнең өстәмә нормативлары белән өлешчә алмаштырылырга мөмкин.

Шәһәр, авыл җирлекләре бюджетларына физик затлар керемнәре буенча салымнан алына торган түләүләрнең өстәмә нормативлары муниципаль районның вәкиллекле органының муниципаль районы бюджеты турындагы карары белән раслана.

19. Физик затлар керемнәренә салымнан алына торган түләүләрнең өстәмә нормативы дотациянең исәпләнгән күләменең (дотациянең исәпләнгән күләме өлешенең) тиешле шәһәр, авыл җирлеге территориясе буенча Татарстан Республикасының берләштерелгән бюджетына күчерелергә тиешле физик затлар керемнәренә салымның бердәй методика нигезендә фаразлана торган күләменә чагыштырмасы буларак исәпләнелә:

$$N^{i}_{НДФЛ} = \frac{ФП^{i}_{план}}{НДФЛ^{i}} \times 100\%,$$

монда:

$N^i_{НДФЛ}$ – i-шәһәр, i-авыл җирлеге өчен физик затлар керемнәренә салымнан түләүләрнең өстәмә нормативының исәпләү күрсәткече;

$ФП^i_{план}$ – i-шәһәр, i-авыл җирлеге бюджетына җирлекләргә район финанс ярдәме фондыннан дотациянең планлаштырыла торган күләме;

$НДФЛ^i$ – i-шәһәр, i-авыл җирлеге буенча Татарстан Республикасының берләштерелгән бюджетына физик затлар керемнәренә салымның чираттагы финанс елына фаразлана торган күләме.

20. Физик затлар керемнәренә салымнан алына торган түләүләрнең өстәмә нормативының исәпләү күрсәткече мөмкин булган максималь нормативтан артып китсә, тиешле район финанс ярдәме фондыннан дотацияләрнең планлаштырыла торган күләме белән физик затлар керемнәренә салымнан алына торган түләүләрнең өстәмә нормативы буенча тапшырыла торган акчалар арасындагы аерма түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$ФП^{i} = ФП^{i}_{план} - \frac{N_{max}}{100\%} \times НДФЛ^{i},$$

монда:

$ФП^i$ – i-шәһәр, i-авыл җирлеге бюджетына җирлекләргә тиешле район финанс ярдәме фондыннан физик затлар керемнәренә салымнан алына торган түләүләрнең өстәмә нормативы билгеләнүен исәпкә алган дотация күләме;

$ФП^i_{план}$– i-шәһәр, i-авыл җирлеге бюджетына җирлекләргә район финанс ярдәме фондыннан дотациянең планлаштырыла торган күләме;

$НДФЛ^i$ – i-шәһәр, i-авыл җирлеге буенча Татарстан Республикасының берләштерелгән бюджетына физик затлар керемнәренә салымның чираттагы финанс елына фаразлана торган күләме;

$N_{max}$– физик затлар керемнәренә салымнан алына торган түләүләрнең өстәмә нормативының процентларда күрсәтелгән максималь зурлыгы.”;

6) 3 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Муниципаль районнарның җирле үзидарә органнарына җирлекләрнең региональ финанс ярдәме фондыннан шәһәр, авыл җирлекләре бюджетларына дотацияләр исәпләү һәм бирү буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен тапшыру турында” Татарстан Республикасы Законына
3 нче кушымта

**__________________ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БУЕНЧА ҖИРЛЕКЛӘРНЕҢ РЕГИОНАЛЬ ФИНАНС ЯРДӘМЕ ФОНДЫННАН ШӘҺӘР, АВЫЛ ҖИРЛЕКЛӘРЕ БЮДЖЕТЛАРЫНА ДОТАЦИЯЛӘР ИСӘПЛӘҮ ҺӘМ БИРҮ БУЕНЧА ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ ВӘКАЛӘТЛӘРЕН ГАМӘЛГӘ АШЫРУ ТУРЫНДА ХИСАП**

| т/с № | Җирлек исеме | Җирлектәге халык саны | ___ елга муниципаль район бюджетында расланган дотация күләме (мең сумнарда) | ___ елда муниципаль район бюджетыннан фактта бирелгән дотация күләме (мең сумнарда) |
|---|---|---|---|---|
| | | | | |
| Барлыгы: | | | | |

Муниципаль районның
вәкаләтле органы җитәкчесе ________ ______________________
имза имза салган затның фамилиясе, инициаллары

Мөһер
урыны

Муниципаль районның вәкаләтле
органы баш бухгалтеры ________

________________________________

имза имза салган затның
фамилиясе,

инициаллары”.

**3 статья**

Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 61 статьясындагы 3 пунктының, 77 статьясының 3 пунктындагы уналтынчы абзацының (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 4 – 5; 2005, № 6 (II өлеш), № 10 (I өлеш), № 12 (IV өлеш); 2006, № 6 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2007, № 8, № 10; 2008, № 8 (III өлеш), № 10 (I өлеш); 2009, № 7 – 8 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2010, № 7 (II өлеш), № 12 (I өлеш); 2011, № 8 (I өлеш), № 11 (I өлеш), № 11 (II өлеш); 2012, № 11 (I өлеш); 2013, № 7, № 10, № 11 (I өлеш); 2014, № 5) гамәлдә булуын 2015 елның 1 гыйнварына кадәр туктатып торырга.

**4 статья**

1. “Татарстан Республикасы Бюджет кодексына үзгәрешләр кертү турында” 2011 елның 18 ноябрендәге 88-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 1 статьясының 17 пунктындагы “б” пунктчасының ундүртенче абзацын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2011, № 11 (I өлеш); 2012, № 11 (I өлеш); 2013, № 10) әлеге Закон үз көченә кергән көннән үз көчен югалткан дип танырга.

2. “Татарстан Республикасы Бюджет кодексына үзгәрешләр кертү турында” 2007 елның 2 августындагы 38-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 1 статьясының 93 пунктындагы кырык дүртенче һәм кырык сигезенче абзацларын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2006, № 6 (I өлеш); 2007, № 8; 2008, № 8 (III өлеш); 2013, № 10) 2016 елның 1 гыйнварыннан үз көчләрен югалткан дип танырга.

**5 статья**

1. Әлеге Закон, әлеге статья белән үз көчләренә керүнең башка вакытлары билгеләнгән нигезләмәләреннән тыш, рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

2. Әлеге Законның 1 статьясындагы 3 пунктының “б” пунктчасы, 10 пункты, 11 пунктының “б” пунктчасы, 12 пунктының “б” һәм “в” пунктчалары, 13 пунктының “а” – “в” һәм “д” пунктчалары, 32 пунктының “в” пунктчасы,

33 пунктының “а” пунктчасы, 45 пункты 2015 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

3. Әлеге Законның 1 статьясындагы 5, 25 пунктлары, 35 пунктындагы “г” пунктчасының өченче абзацы, 38 пунктының “в” – “е” пунктчалары, 39, 40, 42 һәм 44 пунктлары 2016 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

4. Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 49 статьясындагы кырык икенче абзацы, $50^1$ статьясындагы унөченче абзацы (әлеге Закон редакциясендә) 2016 елның 1 гыйнварыннан кулланыла.

5. Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 4 статьясындагы сигезенче абзацы, 5 статьясындагы 2 пункты, 16 статьясындагы 3 һәм 4 пунктлары, $23^1$ статьясындагы $3^1$ пунктының беренче абзацы һәм $3^2$ пункты, 41 статьясындагы икенче һәм җиденче абзацлары, 44 статьясындагы 5 һәм 8 пунктлары, $44^1$, $44^2$, $44^5$ статьялары, $44^6$ статьясындагы 9 һәм 10 пунктлары, $44^8$ статьясы, $44^9$ статьясындагы 4 пункты, $44^{10}$ статьясындагы 1 (муниципаль берәмлекләр буенча исәпләнгән салым керемнәренең 1,3 тапкыр арттырылган уртача дәрәҗәсен кулланудан тыш), 2, 3 (муниципаль берәмлекләр буенча исәпләнгән салым керемнәренең 1,3 тапкыр арттырылган уртача дәрәҗәсен кулланудан тыш) һәм 5 пунктлары, $44^{11}$ – $44^{13}$ статьялары, 47 статьясындагы 1 һәм 2 пунктлары, $97^3$ статьясындагы 2 пунктының өченче абзацы (әлеге Закон редакциясендә), Татарстан Республикасы Бюджет кодексына 2, $2^1$, 5 нче һәм 12 нче кушымталары (әлеге Закон редакциясендә) нигезләмәләре, “Муниципаль районнарның җирле үзидарә органнарына җирлекләрнең региональ финанс ярдәме фондыннан шәһәр, авыл җирлекләре бюджетларына дотацияләр исәпләү һәм бирү буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен тапшыру турында” 2005 елның 22 декабрендәге 132-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (әлеге Закон редакциясендә) нигезләмәләре, 2015 елга, 2016 һәм 2017 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджетыннан башлап, Татарстан Республикасы бюджетын төзегәндә һәм үтәгәндә барлыкка килә торган хокук мөнәсәбәтләренә карата кулланыла.

6. Татарстан Республикасы Бюджет кодексының $44^{10}$ статьясындагы 1 (муниципаль берәмлекләр буенча исәпләнгән салым керемнәренең 1,3 тапкыр арттырылган уртача дәрәҗәсен куллану өлешендә) һәм 3 пунктлары (муниципаль берәмлекләр буенча исәпләнгән салым керемнәренең 1,3 тапкыр арттырылган уртача дәрәҗәсен куллану өлешендә), $60^1$ статьясындагы 3 пунктының $2^1$ һәм 3 пунктчалары, 61 статьясындагы 4 пунктының уникенче абзацы, 77 статьясындагы 4 пункты, $78^1$ статьясындагы 3 пункты, $80^2$ статьясындагы 2 пункты, $97^1$ статьясындагы 3 пункты (әлеге Закон редакциясендә) нигезләмәләре, 2016 елга, 2017 һәм 2018 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджетыннан башлап, Татарстан Республикасы бюджетын төзегәндә һәм үтәгәндә барлыкка килә торган хокук мөнәсәбәтләренә карата кулланыла.

7. 2015 елга, 2016 һәм 2017 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджетын төзегәндә һәм үтәгәндә Татарстан Республикасы Бюджет кодексының $44^1$ һәм $44^2$ статьялары (әлеге Закон редакциясендә) нигезендә билгеләнгән

физик затлар керемнәренә салымнан алына торган түләүләрнең өстәмә нормативларын үзгәртү, шулай ук һәр муниципаль берәмлекнең бюджетына җирлекләрнең бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә дотацияләр, муниципаль районнарның (шәһәр округларының) бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә дотацияләр күләмнәрен, шул исәптән 2014 елга, 2015 һәм 2016 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджетында 2015 һәм 2016 елларга расланганнарын, үзгәртү рөхсәт ителә.

8. Татарстан Республикасы Бюджет кодексының $44^5$ статьясында (әлеге Закон редакциясендә) билгеләнгән чикләү 2016 елның 1 гыйнварына кадәр Татарстан Республикасы бюджетыннан җирле бюджетларның нисбәтлелеген тәэмин итү чараларына ярдәм итүгә дотацияләр күләменә арттырылырга мөмкин.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан,Кремль
2014 елның 18 декабре
№ 127-ТРЗ